# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ҮЧӘЛЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
# УСТАВЫ
# (ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘРЕ БЕЛӘН)

# I БҮЛЕК. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

## 1 статья. Авыл җирлеге һәм аның статусы

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә авыл җирлеге статусы бирелде.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атылышы – Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге (алга таба текстта – авыл җирлеге).

3. «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Азнакай муниципаль районы составына керә.

## 2 статья. Авыл җирлегенең территориаль корылышы

1. Авыл җирлеге территориясе составына түбәндәге торак пунктлары керә: Үчәлле авылы , Якты Күл авылы, Текмәле авылы, Кызыл Йолдыз поселогы.

2. Авыл җирлегенең административ үзәге булып Үчәлле авылы торак пункты тора.

3. Авыл җирлегенең чикләре «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр территорияләренең чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнде.

4. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 3 статья. Авыл җирлегендәге рәсми символлар

1. Авыл җирлегенең тарихи, мәдәни, милли һәм бүтән төрле җирле гореф-гадәтләрне һәм үзенчәлекләрне чагылдыра торган үз гербы бар.

2. Рәсми символларга тасвирлама, алардан файдалану тәртибе «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы тарафыннан раслана торган Авыл җирлеге гербы турында нигезләмәдә билгеләнә.

## 4 статья. Авыл җирлегендә гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыру хокукы

1. Авыл җирлегендә җирле үзидарә Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан җирле референдумнарда, муниципаль сайлауларда катнашу һәм турыдан-туры ихтыяр белдерүнең башка формаларында, шулай ук сайлаулы һәм җирле үзидарәнең әлеге Уставта каралган бүтән органнары аша гамәлгә ашырыла.

2. Гражданнар турыдан-туры да, шулай ук үзләренең вәкилләре аша да, җенесенә, милләтенә, теленә, килеп чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, нинди диндә булуына, ышануларына, иҗтимагый берләшмәләргә каравына бәйсез рәвештә, җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда тигез хокукларга ия.

Авыл җирлеге территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче чит ил гражданнары җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе халыкара шартнамәләренә һәм федераль законнарга ярашлы хокукларга ия була.

3. Һәркем җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларына турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга хокуклы.

4. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, әгәр законда башкача каралмаса, һәркемгә турыдан-туры аның хокукларына һәм ирекләренә кагыла торган документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген, шулай ук гражданнарга авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка төрле тулы һәм төгәл мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

5. Җирле үзидарә органнары, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында» 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка төрле ысул белән халыкка даими рәвештә авыл җирлеген һәм аның аерым территорияләрен үстерүнең әһәмиятле мәсьәләләре турында, уртак файдаланудагы транспорт эше, торак-коммуналь хуҗалык, социаль-мәдәни һәм халыкка төрле хезмәтләр күрсәтүче башка учреждениеләр һәм хезмәтләр челтәрен үстерү, җәмәгать тәртибен саклау һәм табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләрнең торышы турында мәгълүмат җиткерә.

6. Гражданнар, оешмалар, әгәр үзләренең хокуклары һәм ирекләре бозылган дип исәпләсә, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмавын) судта бәхәс итәргә хокуклы.

## 5 статья. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасы

1. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасына авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Башкарма комитеты, авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе, җирле үзидарәнең башка органнары керә.

2. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү әлеге Уставка үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 6 статья. Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре

1. Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) авыл җирлеге бюджеты проектын төзү һәм карау, авыл җирлеге бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшерүдә тоту, авыл җирлеге бюджетын үтәү турында хисап төзү һәм раслау;

2) авыл җирлегенең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

3) авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтендә торучы мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

4) авыл җирлегендәге торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү;

5) авыл җирлегендә яшәүчеләрне элемтә хезмәтләре, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

6) авыл җирлегендә яшәүчеләрнең ялын оештыру һәм аларны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

7) авыл җирлеге территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү, рәсми физик культура-савыктыру һәм Авыл җирлеге спорт чараларын уздыруны оештыру өчен шартлар тәэмин итү;

8) авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру;

9) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшерүдә тоту, аталган кагыйдәләргә туры китереп, авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру;

10) адресацияләү объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, гамәлдән чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яки муниципальара әһәмияттәге, муниципаль районның муниципаль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан гайре) исемнәр, авыл җирлеге чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру;

11) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә булышлык күрсәтү, кече һәм урта эшкуарлык өчен шартлар тудыру;

12) авыл җирлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) җәмәгатьчелек тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә булышлык күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аралап туплау) һәм транспорт белән күчерү буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;

15) йола буенча үткәрелә торган хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту;

16) авыл җирлеге чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су агызуны, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

18) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) каршылыкларны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

19) авыл җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм, гражданнарның уртак файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иркле үтеп керә алуын тәэмин итүне дә кертеп, халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

2. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль районның җирле үзидарә органнары белән Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Азнакай

муниципаль районы бюджетына авыл җирлеге бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен аларга тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

## 7 статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары

1. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) авыл җирлеге музейларын булдыруга;

2) авыл җирлегендә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләрне башкаруга;

3) опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруда катнашуга;

4) авыл җирлеге территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруга;

5) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм авыл җирлеге территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтүгә;

6) авыл җирлеге территориясендә булган муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең мобилизацияле әзерлеге буенча чараларны оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашуга;

7) муниципаль янгын сагы булдыруга;

8) туризм үстерү өчен шартлар тудыруга;

9) кеше хокукларын тәэмин итүне иҗтимагый тикшереп торуны һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм итүгә;

10) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның россиякүләм иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан булдырылган оешмаларга ярдәм итүгә;

11) торак законнарына туры китереп, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наймга алу шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирүгә;

12) көчен югалтты;

13) авыл җирлеге территориясендә яшәүче күзәтүсез хайваннарны тоту һәм асрау буенча чараларны гамәлгә ашыруга;

14) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга;

15) инвалидларның, сәламәтлеге буенча мөмкинлеге чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм итүгә.

2. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 1 өлешендә аталган мәсьәләләрне хәл итәргә, бүтән дәүләт вәкаләтләрен («Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә аларга тапшырылмаганнарын) гамәлгә ашыруда катнашырга, әгәр мондый катнашу федераль законнарда каралган булса, шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелмәгән һәм федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында алар компетенциясеннән чыгарылмаган бүтән мәсьәләләрне авыл җирлеге бюджеты керемнәре, Россия Федерациясе бюджет системасындагы бюджетлардан бирелгән бюджетара трансфертлардан тыш, һәм өстәмә норматив исәпләмә суммалары буенча килгән салым керемнәре хисабына хәл итәргә хокуклы.

**8 статья. Авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлек итүдә катнашуы**

Авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы җирле үзидарә турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**9 статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре**

Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерүгә юнәлдерелгән дәүләт программаларын гамәлгә ашыруда катнашуы;

2) авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары арасында шартнамәләр (килешүләр) төзү;

3) даими яки вакытлыча координация, консультатив, киңәшмә һәм башка төрле эш органнары төзү;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында авыл җирлеге Советының закон чыгару инициативасы;

5) үзара хезмәттәшлек итүнең законнарда билгеләнгән башка формалары.

**10 статья. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу**

1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларына карата таләпләрне, муниципаль хезмәткәр статусын билгеләүне, муниципаль хезмәтне узу шартларын һәм тәртибен дә кертеп, муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы,

әлеге Устав һәм авыл җирлегенең башка төрле муниципаль норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

2. Авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренә карата өстәмә социаль һәм бүтән гарантияләрне бирү шартлары авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларында билгеләнергә мөмкин.

## II БҮЛЕК. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ТУРЫДАН-ТУРЫ ХАЛЫК ТАРАФЫННАН ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛУЫ ҺӘМ ХАЛЫКНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА КАТНАШУ ФОРМАЛАРЫ

### 11 статья. Җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның турыдан-туры катнашуы

Авыл җирлеге халкы җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда турыдан-туры катнаша, түбәндәге формаларда:

1) җирле референдум;

2) муниципаль сайлаулар;

3) җирле үзидарә депутатын, сайлап куела торган вазыйфаи затын чакыртып алу турында тавыш бирү;

4) муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү һәм аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү;

5) гражданнарның хокукый иҗат инициативасы;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә;

7) гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар;

8) гражданнар җыелышы;

9) гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы);

10) гражданнарны сораштыру;

11) җирле әһәмияттәге аеруча әһәмиятле мәсьәләләр хакында халык белән фикер алышу;

12) гражданнарның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итүе;

13) Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формалар.

### 12 статья. Җирле референдум

1. Җирле референдум федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры халык тарафыннан хәл итү максатларында уздырыла.

2. Җирле референдум авыл җирлегенең барча территориясендә «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары

турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә уздырыла.

3. Җирле референдумда катнашу хокукына ия булган гражданнар җирле референдумда катнашу хокукына ия була. Гражданнар җирле референдумда гомуми тигез һәм яшерен тавыш биргәндә турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә катнаша.

4. Җирле референдум уздыру турында карар авыл җирлеге Советы тарафыннан түбәндәгеләр инициативасы буенча кабул ителә:

1) җирле референдумда катнашу хокукына ия булган гражданнарның;

2) уставларында сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашу күздә тотылган һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлгән сайлау берләшмәләренең, башка төрле иҗтимагый берләшмәнең;

3) авыл җирлеге Советының һәм авыл җирлеге Башлыгының, алар тарафыннан уртак күрсәтелгән.

5. Гражданнарның, сайлау берләшмәләренең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең инициативасы буенча җирле референдум билгеләүнең шарты булып әлеге инициативаны хуплап имзалар җыю тора, аларның исәбе авыл җирлеге территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар санының биш процентын тәшкил итәргә тиеш, ләкин 25 имзадан азрак була алмый.

6. Референдум уздыру буенча авыл җирлеге Советы һәм авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан уртак күрсәтелгән инициатива авыл җирлеге Советы карары һәм авыл җирлеге Башлыгы карары белән рәсмиләштерелә. Аталган инициативаны күрсәтү тәртибе авыл җирлеге Советының норматив хокукый актында билгеләнә.

7. Авыл җирлеге Советына җирле референдум уздыру инициативасын күрсәтү турында документлар килгән көннән башлап 30 көн эчендә авыл җирлеге Советы җирле референдум билгели.

Әгәр җирле референдум билгеләнгән срокларда авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнмәсә, референдум гражданнарның, сайлау берләшмәләренең, авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Сайлау комиссиясенең яки прокурорның мөрәҗәгате нигезендә суд тарафыннан билгеләнә. Суд тарафыннан билгеләнгән җирле референдум авыл җирлегенең Сайлау комиссиясе тарафыннан оештырыла, ә аның уздырылуын тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы яки суд тарафыннан җирле референдум уздыруны тәэмин итү йөкләмәсе бирелгән бүтән орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Тавыш бирү йомгаклары һәм җирле референдумда кабул ителгән карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

9. Җирле референдумда кабул ителгән карар авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм кайсы да булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яки авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауны таләп итми.

10. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары, алар арасында әлеге Уставта билгеләнгән вәкаләтләрнең билгеләнгән чикләнешенә туры китереп, җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлүен тәэмин итәләр.

11. Җирле референдум уздыру турында механизм карарга, шулай ук җирле референдумда кабул ителгән карарга федераль законнар нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

## 13 статья. Муниципаль сайлаулар

1. Авыл җирлегендә муниципаль сайлаулар гомуми тигез һәм яшерен тавыш биргәндә турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау максатларында уздырыла.

2. Тавыш бирү көненә 18 яшенә җиткән һәм сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданины, шулай ук тиешле муниципаль берәмлек территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары авыл җирлеге Советына депутат итеп сайлана ала.

3. Муниципаль сайлаулар авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә. Муниципаль сайлауларны билгеләү турында карар тавыш бирү көненә кадәр 90 көннән иртәрәк булмаган һәм 80 көннән соңга калмаган чорда кабул ителергә тиеш. Аталган карар аны кабул иткән көннән башлап 5 көннән соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырып чыгарылырга тиеш. Федераль законнарда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән очракларда, сайлауларны билгеләү турында карар авыл җирлегенең сайлау комиссиясе яки суд тарафыннан кабул ителә.

4. Муниципаль сайлауларга әзерлек һәм аларны уздыру үз компетенцияләре чикләрендә сайлау комиссияләренә йөкләнә.

5. Авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау федераль законнарда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

6. Авыл җирлеге Советы депутатлары бер сайлау округына сайлаучыларның вәкиллекләренең урта нормасы нигезендә төзелә торган бер мандатлы сайлау округлары буенча сайлана.

7. Теркәлгән, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылардан иң күп тавышлар санын туплаган кандидат бер мандатлы сайлау округы буенча сайланган булып танына.

Әгәр авыл җирлеге Советына депутатлар сайлаганда бер мандатлы сайлау округы буенча тавыш бирү бер кандидатура буенча уздырылса, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылардан тавышларның кимендә 50 процентын алган кандидат сайланган булып танына. Теркәлгән кандидатлар тарафыннан алынган тавышлар тигез булганда, элегрәк теркәлгән кандидат сайланган булып санала.

8. Авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау нәтиҗәләре рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

## 14 статья. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү

1. Авыл җирлеге Советы депутаты, шул исәптән авыл җирлеге Башлыгы законда һәм әлеге Уставта билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә сайлаучылар тарафыннан чакыртып алынырга мөмкин.

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында барлык депутат мандатлары яки депутат мандатларының бер өлеше депутатлар тарафыннан биләнгән очракта, сайлау берләшмәләре тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлекләре составында сайланганнарга карата депутатны чакыртып алу кулланылмый.

2. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу нигезләре булып депутатның суд тәртибендә расланган, сайлаучыларның аңа караша ышанычын шик астына куя торган һәм депутат вазыйфаларын яки авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын үтәмәүдә, депутат, авыл җирлеге Башлыгы статусына туры килми торган эшләрне башкаруда һәм Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын һәм бүтән норматив хокукый актларын, әлеге Уставны һәм бүтән муниципаль норматив хокукый актларны башкача бозуларда чагылган, хокукка каршы килә торган конкрет карарлары яки гамәлләре (гамәл кылмавы) тора.

3. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү халык инициативасы буенча уздырыла.

4. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу инициативасын күрсәтү һәм аны хуплап гражданнардан имза җыю өчен муниципаль сайлауларда катнашу хокукына ия булган кимендә 10 кешелек инициатив төркем оештырыла.

5. Инициатив төркем авыл җирлегенең Сайлау комиссиясенә инициатив төркемне теркәү турында үтенеч язуы белән мөрәҗәгать итә. Инициатив төркемнең үтенеч язуында депутатның аны чакыртып алу өчен нигез булып хезмәт иткән, хокукка каршы килә торган конкрет карарына яки гамәленә (гамәл кылмавына) күрсәтеләргә, инициатив төркемдәге һәр әгъзаның һәм авыл җирлегендә аның исеменнән эш итү вәкаләте бирелгән затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, паспортының яки гражданин паспортын алмаштыручы документның, аны биргән органның исемен яки кодын күрсәтеп, сериясе, номеры һәм бирелгән датасы күрсәтелгән булырга тиеш. Инициатив төркемнең үтенеч язуы аталган төркемдәге барлык әгъзалар тарафыннан имзаланырга тиеш. Үтенеч язуына депутатның аталган, хокукка каршы килә торган карарлары яки гамәлләре (гамәл кылмавы) раслана торган суд карары теркәлергә тиеш.

6. Инициатив төркемне теркәү, авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү инициативасын хуплап имза җыю, җыелган имзаларны тикшерү законда җирле референдум уздыру өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

7. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә һәм җирле референдум уздыру өчен законда билгеләнгән тәртиптә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып уздырыла.

8. Авыл җирлеге Сайлау комиссиясе тарафыннан инициатив төркемнең үтенеч язуы каралганда, авыл җирлеге Советы тарафыннан авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү билгеләнгәндә, тиешле депутат аны чакыртып алу өчен нигез сыйфатында күрсәтелгән шартлар буенча аңлатмалар бирергә, кирәкле документларны күрсәтергә хокуклы. Күрсәтелгән депутатка алдан ук, Сайлау комиссиясе, авыл җирлеге Советы утырышы уздырыласы көнгә кадәр

кимендә өч көн алдан, аны уздыру вакыты һәм урыны турында язмача хәбәр ителергә тиеш.

9. Авыл җирлеге Советы депутаты аны чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырылганда, аны чакыртып алу өчен нигез сыйфатында күрсәтелгән шартлар буенча сайлаучыларга аңлатмалар бирү максатларында, инициатив төркем белән тигез шартларда агитация алып бару хокукына ия була.

10. Авыл җирлеге Советы депутаты, шул исәптән авыл җирлеге Башлыгы, әгәр аны чакыртып алу өчен тиешле сайлау округында теркәлгән сайлаучыларның кимендә яртысы тавыш бирсә, чакыртып алынган булып санала.

11. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

12. Сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын рәсми уздырганнан соң 5 көнлек срокта инициатив төркемгә, авыл җирлеге Советына һәм авыл җирлеге Советының тиешле депутатына аны чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында язмача хәбәр итә.

## 15 статья. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү

1. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү авыл җирлеге чикләрен аталганча үзгәртүгә, аны үзгәртеп коруга халыктан ризалык алу максатларында уздырыла.

2. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү авыл җирлегенең барча территориясендә яки «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда аның территориясенең бер өлешендә уздырыла.

3. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә һәм федераль законда һәм «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып уздырыла.

4. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү, әгәр анда авыл җирлеге халкының яки авыл җирлегенең сайлау хокукына ия булган өлешенең яртысыннан артыгы катнашса, узган дип танылa. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртүгә, авыл җирлеген үзгәртеп коруга ризалык, әгәр аталган үзгәртү, үзгәртеп кору өчен тавыш бирүдә катнашкан халыкның яки авыл җирлеге өлешенең яртысыннан артыгы тавыш биргән булса, халыктан алынган дип санала.

5. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү йомгаклары рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

## 16 статья. Гражданнарның хокукый иҗат инициативасы

1. Гражданнар әлеге Уставта һәм авыл җирлеге Советы норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә хокукый иҗат инициативасына хокуклы.

2. Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булганнары арасында 3 проценттан артмаган күләмдә сайлау хокукына ия булган гражданнар төркеме хокукый иҗат инициативасы белән чыга ала.

3. Хокукый иҗат инициативасын гамәлгә ашыру максатларында гражданнар түбәндәгеләргә хокуклы:

– хокукый иҗат инициативасы турында фикер алышу һәм аны чыгару буенча яшәү (эш) урыны буенча гражданнарның җыелышларын һәм бүтән коллектив чараларны оештырырга һәм уздырырга;

– хокукый иҗат инициативасын чыгаруга теләктәшлек максатында имза җыю буенча инициатив төркемнәр булдырырга;

– хокукый иҗат инициативасын күрсәтүне хуплап, законнарга каршы килми торган ысуллар белән авыл җирлегендә яшәүчеләрдән имза җыярга һәм агитация уздырырга.

4. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары хокукый иҗат инициативасын гамәлгә ашырганда гражданнарга ярдәм итәргә бурычлы.

5. Гражданнарның хокукый иҗат инициативасын тормышка ашыру тәртибендә чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты авыл җирлеге Советы тарафыннан аның ачык утырышында, авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан үзләренең әлеге Уставта билгеләнгән компетенцияләренә туры китереп, аны чыгарган көннән башлап өч ай эчендә каралырга тиеш.

6. Гражданнарның хокукый иҗат инициативасын тормышка ашыру тәртибендә чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын карау процедурасы тиешенчә авыл җирлеге Советы Регламенты, авыл җирлеге Башлыгының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

## 17 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә

1. Авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турыдан-туры халык тарафыннан гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен уздыру юлы белән, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә органнары булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнар яши торган түбәндәге территорияләр чикләрендә гамәлгә ашырыла: күпфатирлы торак йорт подъезды; күпфатирлы торак йорт; торак йортлар төркеме; торак микрорайон; авыл җирлеге булып тормаган авыл торак пункты; гражданнар яши торган бүтән территорияләр.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территориянең чикләре авыл җирлеге Советы тарафыннан әлеге территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча билгеләнә.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория аналогик башка территория составына керә алмый.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә үзенең уставы нигезендә юридик зат була ала һәм коммерциясез оешма оешу-хокукый формасында дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында түбәндәгеләр билгеләнә:

1) ул гамәлгә ашырыла торган территория;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең максатлары, бурычлары, формалары һәм төп юнәлешләре;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын формалаштыру тәртибе, аларның вәкаләтләрен туктату, аларның хокуклары һәм бурычлары, вәкаләтләренең срогы;

4) карарлар кабул итү тәртибе;

5) мөлкәт сатып алу тәртибе, шулай ук аталган мөлкәттән һәм финанс чараларыннан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе;

6) территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруны туктату тәртибе.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге мәсьәләләре буенча гражданнарның җыелышлары, конференцияләре аның уставына туры китереп чакыртыла.

8. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру һәм аны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнарның җыелышы, әгәр анда тиешле территориядә яшәүче, уналты яшенә җиткән халыкның кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы булып санала.

Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру һәм аны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнарның конференциясе, әгәр анда тиешле территориядә яшәүче, уналты яшенә җиткән халыкның кимендә яртысын күрсәтүче, гражданнарның җыелышларында сайланган делегатларның кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының, конференциясенең искәрмәле вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарә керемнәре һәм чыгымнары сметасын һәм аларны үтәү турында хисап раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турында хисаплар карау һәм аларны раслау.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары:

1) тиешле территориядә яшәүче халык мәнфәгатьләрен күрсәтә;

2) гражданнарның җыелышларында һәм конференцияләрендә кабул ителгән карарларның үтәлүен тәэмин итә;

3) территорияне төзекләндерү буенча хуҗалык эшчәнлеген, тиешле территориядә яшәүче гражданнарның социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән бүтән хуҗалык эшчәнлеген күрсәтелгән гражданнарның акчасы хисабына да, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә

органнары һәм җирле үзидарә органнары арасындагы шартнамә нигезендә җирле бюджет акчаларын файдаланып та гамәлгә ашырырга мөмкин;

4) авыл җирлеге органнарына (авыл җирлеге Советына, авыл җирлеге Башлыгына һәм авыл җирлеге Башкарма комитетына) әлеге органнар һәм аталачак актларны кабул итү компетенциясе бирелгән җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан каралырга тиешле муниципаль норматив хокукый актларны кертергә хокуклы.

11. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе, җирле бюджеттан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе әлеге Уставта һәм авыл җирлеге Советының норматив хокукый актында билгеләнә.

## 18 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә кую тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә кую максатларында гражданнарның, авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының инициативасы буенча территориаль иҗтимагый үзидарә уставы проектын эшләүне гамәлгә ашыручы һәм чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру күздә тотылган территориядә яшәүче гражданнар җыелышын чакыртуны оештыручы гражданнарның инициатив төркеме төзелә.

2. Гражданнар җыелышы тиешле авыл җирлеге территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарә булдыру турында карар кабул итә, аның уставын кабул итә, шулай ук авыл җирлеге Советында территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәтүгә бәйле мәсьәләләрдә гражданнар җыелышы исеменнән эш йөртергә вәкаләтле вәкилне (вәкилләрне) билгели.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә авыл җирлеге Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә уставы теркәүгә алынган вакыттан башлап гамәлгә куелган дип санала.

## 19 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү өчен гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) тарафыннан авыл җирлеге Башлыгына түбәндәгеләр тапшырыла:

гражданнар җыелышының барлык вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүгә алу турында гариза;

территориаль иҗтимагый үзидарә булдыру турында карар кабул ителгән гражданнар җыелышы беркетмәсе, һәр вәкаләтле вәкилнең фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, паспортының яки гражданин паспортын алмаштыра торган документының сериясен, номерын һәм бирелгән датасын, яшәгән урыны буенча адресын күрсәтеп;

ике нөсхәдә территориаль иҗтимагый үзидарә уставы.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән документлардан тыш башка документларны тапшыру турында таләп итү – рөхсәт ителми.

Вәкаләтле вәкилгә документларны алу турында аларның исемлеген һәм алыну датасын күрсәтеп язу тапшырыла.

3. Авыл җирлеге Башлыгы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында документлар килгән көннән башлап ике атналык срокта аның беренчел каралуын һәм уставны теркәү турында яки аны теркәүдән баш тарту турында авыл җирлеге Советы карары проекты әзерләүне оештыра.

4. Гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкилләре территориаль иҗтимагый үзидарә уставын беренчел карауда һәм киңәшмә тавыш бирү хокукы белән авыл җирлеге Советы утырышында катнашырга хокуклы.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан алынган көннән башлап 30 көн эчендә авыл җирлеге Советы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү турында яки аны теркәүгә алудан баш тарту турында карар кабул итә. Уставны теркәүгә алудан баш тарту дәлилле булырга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүгә алудан баш тарту нигезе булып территориаль иҗтимагый үзидарә уставындагы нормаларның Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, авыл җирлеге Уставына, бүтән муниципаль норматив хокукый актларга каршы килүе тора.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыруның максатка ярашлы булмавы белән нигезләп, территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүгә алудан баш тарту рөхсәт ителми.

8. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүгә алу мәсьәләсендә авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән дәлилле карар өч көн эчендә рәсми рәвештә язмача формада гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиленә (вәкаләтле вәкилләренә) җиткерелергә тиеш.

9. Авыл җирлеге Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүгә алу турында карар кабул ителгән очракта, уставның аны теркәүгә алу турында тамгасы белән бер нөсхәсе гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиленә тапшырыла, икенче нөсхәсе авыл җирлеге Советында саклана.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставына кертелә торган үзгәрешләр әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә авыл җирлеге Советы тарафыннан теркәүгә алынырга тиеш. Аталган үзгәрешләр аларны теркәүгә алган көннән башлап үз көченә керә.

## 20 статья. Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль норматив хокукый актларның проектлары турында авыл җирлеге халкы белән фикер алышу өчен авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан гавами тыңлаулар уздырылырга мөмкин.

2. Гавами тыңлаулар халык, авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча уздырыла.

Халык яки авыл җирлеге Советы инициативасы буенча уздырыла торган тыңлаулар – авыл җирлеге Советы тарафыннан, ә авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Гавами тыңлауларга түбәндәгеләр чыгарылырга тиеш:

1) авыл җирлегенең Устав проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, Уставка үзгәрешләр фәкать Уставта беркетелә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга туры китерү максатларында гына кертелгән очраклардан тыш;

2) авыл җирлеге бюджеты проекты һәм аны үтәү турында хисап;

3) авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерү стратегиясе проекты;

4) авыл җирлеген үзгәртеп кору турында мәсьәләләр, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә авыл җирлеген үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән яки гражданнар җыеннарында чагылдырылган рәвештә авыл җирлеге халкыннан ризалык алу таләп ителсә.

4. Гавами тыңлауларны уздыру турында карар тиешле орган яки авыл җирлеге вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль норматив хокукый акт проекты каралган көннән башлап 20 көн узганчы кабул ителергә тиеш, әгәр гамәлдәге законнарда башкасы билгеләнмәсә.

5. Гавами тыңлаулар уздыру турында карар, аларны уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, һәм гавами тыңлаулар өчен чыгарыла торган тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлауларны уздыру көненә кадәр 7 көн калганчы бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш, әгәр гамәлдәге законнарда башкасы билгеләнмәсә.

6. Гавами тыңлаулар уздыру турында карар бастырып чыгарылган көннән башлап һәм аларны уздырган көннән башлап авыл җирлегендә яшәүчеләр авыл җирлеге Башлыгына гавами тыңлауларга кертелә торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, шул исәптән гавами тыңлауларга кертелә торган муниципаль норматив хокукый акт проектына карата төзәтмәләр һәм бүтән тәкдимнәр җибәрергә хокуклы. Авыл җирлеге Башлыгы килгән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне гомумиләштерүне оештыра. Аталган тәкъдимнәр һәм кисәтүләр гавами тыңлауларда катнашучылар игътибарына җиткерелә.

7. Гавами тыңлаулар муниципаль норматив хокукый акт проекты каралган көнгә кадәр 7 көннән соңга калмыйча уздырыла. Гавами тыңлаулар белгечләрне, экспертларны, мәнфәгатьле затларны чакыртып уздырыла. Гавами тыңлауларда авыл җирлегендә яшәүче теләсә кем катнашырга хокуклы, әгәр гамәлдәге законнарда башкасы билгеләнмәсә.

8. Гавами тыңлауларны уздыру йомгаклары буенча тәкъдимнәр кабул ителә, алар гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проектын кабул итү компетенциясенә ия булган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан зарури каралырга тиеш.

9. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 көннән соңга калмыйча бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш, әгәр гамәлдәге законнарда башкасы каралмаса.

10. Гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана торган Гавами тыңлаулар турында нигезләмәдә билгеләнә;

11. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзеп тотыру кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзеклəндерү кагыйдәләре проектлары, аталган расланган документларның берәрсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалану төренә рөхсәт бирү турында карарларның проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәтле төзү, үзгәртеп кору буенча чик дәрәҗә параметрлардан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында карарларның проектлары, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәтле файдалануның бер төреннән мондый файдалануның икенче төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча, җирдән файдалану һәм төзеп тотыруның расланган кагыйдәләре булмаганда, иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар уздырыла, аларны оештыру һәм уздыру тәртибе авыл җирлеге Уставында һәм (яки) авыл җирлеге Советының норматив хокукый актында шәһәр төзү эшчәнлеге турында законнар нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.

## 21 статья. Гражданнар җыелышы

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр турында фикер алышу, халыкка җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлеге җирле үзидарә вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында мәгълүмат ирештерү, авыл җирлеге территориясенең бер өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашыру өчен гражданнарның җыелышлары уздырылырга мөмкин. Гражданнарның җыелышлары микрорайоннар, торак биләмәләре, кварталлар, урамнар, торак йортлар буенча чакыртыла.

2. Гражданнар җыелышы халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган очракларда уздырыла.

3. Авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча уздырыла торган гражданнар җыелышы тиешенчә авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы буенча уздырыла торган гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, тиешле территориядә яшәүче һәм җыелышта катнашу хокукына ия булган халыкның кимендә 10 процентын тәшкил иткән күләмдә гражданнар төркеме, әлеге территорияләрдә урнашкан предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренең язмача тәкъдиме буенча билгеләнә.

Гражданнар җыелышын уздыру турында тәкъдимдә карау өчен чыгарыла торган мәсьәләләр исемлеге, җыелыш уздыруның күзалланган вакыты һәм урыны булырга тиеш. Тәкъдим вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланган булырга тиеш, ә әгәр җыелыш уздыру инициативасы белән гражданнар төркеме мөрәҗәгать итә икән – һәркайсының фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, яшәү урыны буенча адресын күрсәтеп, әлеге гражданнар тарафыннан.

Авыл җирлеге Советы гражданнар җыелышын уздыру турында кертелгән тәкъдимне үзенең киләсе утырышында карый.

Авыл җирлеге Советы максатка ярашлы булмавын нигезләп, гражданнар җыелышын уздырудан баш тартырга хокуклы түгел.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм уздыру тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставында билгеләнә.

6. Гражданнар җыелышын уздыру вакыты һәм урыны турында һәм фикер алышу өчен кертелә торган мәсьәләләр турында тиешле территориядә яшәүчеләргә моның өчен массакүләм мәгълүмат чараларын, почтадан хәбәр итүне, фатирлар (ишегаллары) буйлап йөреп чыгуны, белдерүләр һәм мөмкин булган бүтән чараларны кулланып, җыелыш уздыру көненә кадәр 7 көннән соңга калмыйча хәбәр ителә.

Гражданнар җыелышын әзерләүне һәм уздыруны авыл җирлеге Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышлар эшендә әлеге территориядә яшәүче, сайлау хокукына ия булган гражданнар катнашырга хокуклы. Җыелышта катнашу хокукына ия булган гражданнарның гомуми саны Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча муниципаль сайлауларны уздырганда кулланыла торган Россия Федерациясе гражданнарын теркәү исәбенә алу белешмәләре нигезендә ачыклана.

Әгәр анда җыешлыштта катнашу хокукына ия булган гражданнар арасыннан кимендә өчтән бер өлеше катнашса, гражданнар җыелышы тулы хокуклы була.

Җыелыш карарлары җыелышта катнашкан гражданнарның күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә.

8. Гражданнар җыелышы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарә вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләрне кабул итәргә, шулай ук авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышы исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларны сайларга мөмкин.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча уздырыла торган гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә уставында алар компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

10. Гражданнар җыелышына кабул ителгән мөрәҗәгатьләр, язмача җавап җибәреп, мөрәҗәгатьләрдә булган мәсьәләләрне хәл итүгә компетенцияле булган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан зарури каралырга тиеш.

11. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм уздыру тәртибе, шулай ук гражданнар җыелышының вәкаләтләре федераль законда, әлеге Уставта һәм авыл җирлеге Советының норматив хокукый актында билгеләнә.

12. Гражданнар җыелышының йомгаклары аны уздырганнан соң бер айлык срокта рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

## 22 статья. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр турында фикер алышу һәм авыл җирлегендәге барлык халык вәкилләренең фикерен ачыклау зарурлыгы булган очракта уздырыла. Авыл

җирлегенең тиешле территориаль өлешләрендә яшәүчеләр исәбеннән гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышын чакырту катлаулы булган очракларда уздырыла.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган тәртиптә һәм очракларда билгеләнә һәм уздырыла.

2. Гражданнар конференциясен (делегатлар җыелышын) билгеләү һәм уздыру, делегатларны сайлау тәртибе әлеге Уставта һәм (яки) авыл җирлеге Советының норматив хокукый актында билгеләнә.

3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча уздырыла. Авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча уздырыла торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) тиешенчә авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә. Халык инициативасы буенча уздырыла торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), әгәр анда сайланган депутатларның яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы булып санала. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) карарлары конференциядә катнашкан делегатларның күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә.

6. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) йомгаклары аны уздырганнан соң бер айлык срокта бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

## 23 статья. Гражданнарны сораштыру

1. Гражданнарны сораштыру халык фикерен ачыклау һәм җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә аларны исәпкә алу өчен авыл җирлегенең барча территориясендә яки территориясенең бер өлешендә уздырыла.

Сораштыру нәтиҗәләре киңәш итү холкына ия була.

2. Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукына ия булган авыл җирлеге халкы катнашырга хокуклы була.

3. Гражданнарны сораштыру түбәндәгеләр инициативасы буенча уздырыла:

1) авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге Башлыгы – җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары – авыл җирлеге җирләренең максатчан билгеләнешен республика һәм республикара әһәмиятендәге объектлар өчен үзгәртү турында карарлар кабул иткәндә гражданнар фикерен исәпкә алу өчен.

4. Гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе әлеге Уставта һәм (яки) Татарстан Республикасы законы нигезендә авыл җирлеге Советының норматив хокукый актларда билгеләнә.

5. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турында карар авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Авыл җирлеге Советының гражданнарны сораштыруны билгеләү турында карарында түбәндәгеләр билгеләнә:

1) сораштыруны уздыру датасы һәм сроклары;

2) сораштыруны уздырганда тәкъдим ителә торган мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) тәгъбирләнеше;

3) сораштыруны уздыру методикасы;

4) сораштыру кәгазенең формасы;

5) сораштыруда катнашучы авыл җирлеге халкының минималь исәбе.

6. Авыл җирлегендә яшәүчеләргә гражданнарны сораштыру уздырылачагы турында аны уздыру көненә кадәр кимендә 10 көн алдан хәбәр ителә.

7. Гражданнарга сораштыру уздыруны әзерләүгә бәйле чараларны финанслау түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) авыл җирлеге бюджеты акчасы хисабына – авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары инициативасы буенча сораштыру уздырылганда;

2) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабына – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча сораштыру уздырылганда.

8. Сораштыру йомгаклары аны уздырганнан соң бер айлык срокта бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш. Сораштыру нәтиҗәләре белән авыл җирлегендә яшәүче теләсә кем танышып чыгарга хокуклы. Сораштыру нәтиҗәләре авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле карарлар кабул ителгәндә исәпкә алынырга тиеш.

### 24 статья. Җирле әһәмияттәге аеруча әһәмиятле мәсьәләләр хакында халык белән фикер алышу

1. Муниципаль норматив хокукый актларның проектларын һәм җирле әһәмияттәге аеруча әһәмиятле мәсьәләләрне халык арасында фикер алышуга чыгару турында карар тиешле территориядә яшәүче гражданнарның үз инициативасы яки таләбе буенча авыл җирлеге Советы тарафыннан авыл җирлеге Советы билгели торган тәртиптә кабул ителә.

2. Муниципаль норматив хокукый акт проектының тексты һәм халык арасында фикер алышу өчен чыгарыла торган мәсьәләләр буенча бүтән материаллар аларны халык арасында фикер алышуга чыгару турында карар кабул ителгәннән соң 5 көннән соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында бастырыла, авыл җирлегендә яшәүчеләргә таратыла, халыкка танышып чыгу өчен мөмкин булган урыннарда урнаштырыла, бүтән ысуллар белән халыкка белдерелә.

3. Мәсьәләне халык арасында фикер алышуга чыгару белән бер үк вакытта авыл җирлеге Советы фикер алышу барышында килгән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне карау эшен оештыру срогын һәм тәртибен билгели, күрсәтелгән максат өчен махсус комиссия төзи.

4. Авыл җирлеге Советы үзенә кертелә торган муниципаль норматив хокукый актларның проектлары һәм җирле әһәмияттәге аеруча әһәмиятле башка мәсьәләләр турында фикер алышуларны тәэмин итә, моның өчен кирәкле шартларны тудыра.

5. Халык арасында фикер алышуга чыгарылган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр авыл җирлеге Советына юллана.

6. Муниципаль норматив хокукый актларның проектлары һәм җирле әһәмияттәге аеруча мөһим башка мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр авыл җирлеге Советы тарафыннан карала.

7. Халык арасында фикер алышу йомгаклары турында халыкка бер айлык срокта хәбәр ителә.

## 25 статья. Гражданнарның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итүе

1. Гражданнар шәхсән дә һәм коллектив белән дә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда каралырга тиеш.

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм срокларын бозган өчен җирле үзидарә вазыйфаи затлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы була.

## 26 статья. Авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан турыдан-туры җирле үзидарәне гамәлгә ашыруның һәм аны гамәлгә ашыруда катнашуның башка формалары

1. Федераль законнар нигезендә халык тарафыннан турыдан-туры җирле үзидарәне гамәлгә ашыруның һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуының әлеге Уставта каралган формалары белән беррәттән, гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган формаларында да катнашырга хокуклы.

2. Авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан турыдан-туры җирле үзидарәне гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуы законлы, ирекле булу принципларына нигезләнә.

Җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлеге җирле үзидарә вазыйфаи затлары авыл җирлегендә яшәүчеләргә турыдан-туры җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуына ярдәм итәргә бурычлы.

# III БҮЛЕК. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## 27 статья. Авыл җирлеге Советы – авыл җирлеге җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы

1. Авыл җирлеге Советы авыл җирлеге җирле үзидарәсенең даими эшләүче, сайлаулы, коллегиаль вәкиллекле органы булып тора.

2. Авыл җирлегенең рәсми аталышы – «Авыл җирлегенең Үчәлле Советы».

3. Авыл җирлеге Советының вәкаләтләр срогы – 5 ел.

4. Авыл җирлеге Советы авыл җирлеге халкы каршында хисап тота һәм тикшерүдә тора.

5. Авыл җирлеге Советының үз аталышы белән мөһере, бланклары бар.

6. Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнар классификациясенә туры китереп, авыл җирлеге бюджетында аерым юлда карала.

## 28 статья. Авыл җирлеге Советының составы

1. Авыл җирлеге Советы бер мандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайлана торган 7 депутаттан тора.

2. Авыл җирлеге Советы аның составына авыл җирлеге Советына билгеләнгән исәптәге депутатларның кимендә өчтән ике өлеше сайланганда тулы хокуклы була.

## 29 статья. Авыл җирлеге Советы депутатының, авыл җирлеге җирле үзидарәсенең сайлаулы органы әгъзасының, авыл җирлеге җирле үзидарәсенең сайлаулы вазыйфаи затының статусы

1. Авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләре аны сайлаган көннән башлана һәм яңа чакырылыш авыл җирлеге Советы эшли башлаган көнгә кадәр туктатыла.

2. Авыл җирлеге Советы депутаты, төп эш урыны буенча эш һәм хезмәт вазыйфаларын үтәп, депутатлык эшчәнлеге белән берләштереп, азат ителми торган нигездә эшли, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш.

3. Депутат, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче бүтән зат «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләмәләрне, тыюларны сакларга, бурычларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затының, муниципаль вазыйфа биләүче бүтән затның вәкаләтләре, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларына Россия Федерациясе

территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләмәләрне, тыюларны сакламаган, бурычларны үтәмәгән очракта, вакытыннан алда туктатыла.

Авыл җирлеге Советы депутатлары, авыл җирлеге җирле үзидарәсенең сайлаулы органы әгъзалары, авыл җирлеге җирле үзидарәсенең сайлаулы вазыйфаи затлары түбәндәгеләрне бурычлы:

– Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатыннарының (ирләренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга;

– Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында хәбәр итәргә, шулай ук мондый каршылыкны булдырмый калу яки җайга салу буенча чаралар күрергә.

4. Авыл җирлеге Советы депутатына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә үзенең вәкаләтләрен каршылыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырыла.

5. Авыл җирлеге Советы депутаты авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана торган Депутат этикасы кагыйдәләрен сакларга тиеш, шул исәптән аларда депутатның түбәндәге вазыйфалары булырга тиеш:

1) шәхсән аңа яки аның якын туганнарына кагыла торган мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусыннан файдаланмаска;

2) депутат бурычларының объектив үтәлүендә шик тудырырга мөмкин булган тәртиптә тотылырга, шулай ук үзенең репутациясенә яки авыл җирлеге Советы абруена зыян китерергә сәләтле каршылыклы хәлләрдән качарга;

3) мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу ыркынычы булганда – шәхси кызыксынучанлык депутат бурычларын объектив үтәүгә йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган хәлләрдә, – бу хакта авыл җирлеге Советына хәбәр итәргә һәм аның әлеге мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калуга яки җайга салуга юнәлдерелгән карарын үтәргә;

4) авыл җирлеге Советында билгеләнгән гавами чыгыш ясау кагыйдәләрен сакларга;

5) федераль законда конфиденциаль холыклы белешмәләргә кертелгән, депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа билгеле булган белешмәләрне таратмаска һәм депутат эшчәнлегенә бәйле булмаган максатларда файдаланмаска;

6) депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләүләр, ссудалар, хезмәтләр, күңел ачу, ял өчен, транспорт чыгымнарына түләүләр һәм бүтән төрле бүләкләүләр) алмаска.

6. Даими нигездә үзләренең вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи заты түбәндәгеләрне хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлары аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашырга («Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләре идарәсендә, сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан, съездда (конференциядә) яки бүтән иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш), федераль законнарда каралган очраклардан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә оешма белән идарә итү җирле үзидарә органы исеменнән гамәлгә ашырылган очраклардан тыш;

2) укыту, фәнни һәм башка төрле иҗат эшчәнлегеннән тыш, бүтән түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Бу чакта укыту, фәнни һәм бүтән иҗат эшчәнлеге, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында бүтәне каралмаган булса, чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

3) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаса, хөкүмәткә карамаган коммерциясез чит ил оешмаларының һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш итүче структур бүлекчәләренең идарә органнары, попечительләр һәм күзәтүчеләр советлары, бүтән органнары составына керергә.

7. Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары нигезендә депутат, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи заты тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләр турында белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын тикшерү Татарстан Республикасы Президенты карары буенча Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

8. Әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләмәләрне, тыюларны сакламау, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты депутатның, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән тиешле карар кабул итүгә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки судка мөрәҗәгать итә.

## 30 статья. Авыл җирлеге Советы депутатының сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәте

1. Авыл җирлеге Советы депутаты сайлаучылар, шулай ук аның сайлау округы территориясендә урнашкан предприятиеләрнең, оешмаларның коллективлары, дәүләт һәм бүтән органнар белән элемтәдә тора.

2. Авыл җирлеге Советы депутаты сайлаучылар алдында үзенең эше турында хисап тота һәм аларга даими рәвештә авыл җирлеге Советы эше турында мәгълүмат җиткерә, шулай ук сайлаучыларны кабул итә.

3. Авыл җирлеге Советы депутаты авыл җирлегендә яшәүчеләрнең законлы хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча законнарда каралган чараларны күрергә, шул исәптән алардан килгән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карарга, аларда булган мәсьәләләрне дөрес һәм үз вакытында хәл итүгә ярдәм итәргә бурычлы.

## 31 статья. Яңадан сайланган авыл җирлеге Советы эшен оештыру

1. Яңа чакырылыш авыл җирлеге Советы авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән исәбендәге депутатларның кимендә өчтән икесе сайланган көннән соң утыз көннән соңга калмыйча беренче утырышка җыела. Авыл җирлеге Советының сайлаулардан соңгы беренче утырышы авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан чакыртыла, ә ул булмый торган очракта – авыл җирлегенең Сайлау комиссиясе тарафыннан.

2. Авыл җирлеге Советының сайлаулардан соңгы беренче утырышын авыл җирлегенең яңа Башлыгы сайланганчыга кадәр авыл җирлеге Советының яше буенча өлкәнрәк депутаты ача һәм алып бара.

## 32 статья. Авыл җирлеге Советының компетенциясе

Авыл җирлеге Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) авыл җирлеге уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр кертү;

2) законнар нигезендә авыл җирлеге территориясендә гомуми зарури кагыйдәләр билгеләү;

3) авыл җирлеге бюджетын һәм аны үтәү турында хисап раслау;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аларны түләүдә ташламалар бирү;

5) авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау;

6) авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору турында инициатива күрсәтү;

7) авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауны билгеләү һәм авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау буенча сайлау округлары схемасын раслау;

8) җирле референдум билгеләү;

9) авыл җирлеге Башлыгын сайлау;

10) авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләү, аның отставкага китүен кабул итү;

11) авыл җирлеге Советы депутатлары арасыннан муниципаль район Советына авыл җирлеге вәкилен сайлау;

12) авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасын раслау, аның хезмәткәрләренең чик исәбен билгеләү;

13) авыл җирлеге Сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү;

14) авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору буенча тавыш бирүне, авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү;

15) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру;

16) авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтендә торган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен, шул исәптән федераль законнар нигезендә аны хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү; читләштерелүе килешү буенча яки авыл җирлеге Советы раслаганнан соң гамәлгә ашырыла торган муниципаль мөлкәт төрләре исемлеген билгеләү;

17) муниципаль предприятиеләрне булдыру, үзгәртеп кору һәм бетерү турында, шулай ук муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү;

18) авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлекне оештыруда катнашуы тәртибен билгеләү;

19) авыл җирлегенең Ревизия комиссиясен формалаштыру;

20) авыл җирлеге башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итү;

21) авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең үтәлүен тикшерүдә тоту;

22) авыл җирлеген территориаль планлаштыру документларын, авыл җирлеген шәһәр төзелеше буенча проектлауның җирле нормативларын, җирдән файдалану һәм авыл җирлеге территориясен төзеп тотыру кагыйдәләрен, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә башка төрле шәһәр төзелеше документациясен раслау;

23) авыл җирлеге территориясендә торак пунктларының урамнарына һәм башка өлешләренә исем бирү һәм исемнәрен үзгәртү турында мәсьәләләрне хәл итү;

24) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм матди ресурсларның җирле резервларын булдыру һәм файдалану тәртибен билгеләү;

25) муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибен билгеләү;

26) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына авыл җирлеге бюджетыннан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;

27) автономияле коммерциясез оешмалар һәм фондлар формасында коммерциясез оешмалар булдыру турында карарлар кабул итү;

28) җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

29) авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлек башлыгыннан, җирле хакимият башлыгыннан аларның эшчәнлек, җирле хакимият һәм муниципаль берәмлек башлыгының ведомство буйсынуында торучы бүтән җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан куелган мәсьәләләрнең хәл ителүе турында ел саен тапшырыла торган хисапларны тыңлый;

30) энергияне сак куллану һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программалар раслау һәм гамәлгә ашыру, андагы урыннар авыл җирлеге чикләрендәге муниципаль торак фондын тәшкил итүче күпфатирлы йортларга энергетика тикшерүен уздыруны оештыру, энергияне сак куллану турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнарда каралган бүтән чараларны оештыру һәм уздыру;

31) шәхси массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә кую;

32) авыл җирлеге Уставын һәм авыл җирлеге Советы карарларын аңлату;

33) авыл җирлеге Советы Регламентын һәм үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча бүтән карарлар кабул итү;

34) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары карамагына кертелгән бүтән вәкаләтләр, шулай ук әлеге Уставта авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән бүтән вәкаләтләр;

35) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау.

## 33 статья. Авыл җирлеге Советының эш тәртибе

1. Авыл җирлеге Советының эш тәртибе әлеге Уставта һәм авыл җирлеге Советы Регламентында билгеләнә.

2. Авыл җирлеге Советы эшенең төп формасы булып авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр хәл ителә торган аның утырышлары тора.

3. Авыл җирлеге Советы сессиясе, әгәр анда сайланган депутатлар арасыннан кимендә 50 проценты катнашса, тулы хокуклы була.

4. Авыл җирлеге Советының чираттагы утырышы зарурлык булуга карап, ләкин өч айга бер мәртәбәдән артмаган ешлыкта уздырыла. Чираттан тыш утырышлар авыл җирлеге Башлыгы яки авыл җирлеге Советына билгеләнгән депутатлар исәбендә кимендә өчтән бер өлешен тәшкил иткән депутатлар төркеме инициативасы буенча чакыртыла.

5. Совет утырышлары авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан чакыртыла. Авыл җирлеге Советы депутатларына һәм чакырылган затларга чираттагы утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында аны уздырырга кимендә биш көн алдан, ә чираттан тыш утырыш уздырылганда – кимендә бер көн алдан хәбәр ителә.

6. Авыл җирлеге Советының һәр утырышында утырыш беркетмәсе алып барыла. Утырыш беркетмәсенә утырышны уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында белешмәләр кертелә, карала торган барлык мәсьәләләр санап чыгыла һәм тавыш бирү йомгакларын күрсәтеп, кабул ителгән барлык карарлар теркәлә. Авыл җирлеге Советы утырышы беркетмәсенә авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан кул куелганнан соң, аның белән авыл җирлегендә яшәүче теләсә кем танышып чыга ала.

7. Авыл җирлеге Советы утырышларында һәр депутат бер тавышка ия. Авыл җирлеге Советы депутаты тавыш бирүгә үз хокукын шәхсән гамәлгә ашыра. Авыл җирлеге Советы утырышларында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемләп) һәм яшерен була ала. Тавыш бирүнең һәр төрен куллану очраклары әлеге Уставта, авыл җирлеге Советы регламентында билгеләнә.

## 34 статья. Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру

1. Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыруны авыл җирлеге Башлыгы гамәлгә ашыра.

2. Авыл җирлеге Советы Регламенты нигезендә авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен депутатлар арасыннан, авыл җирлеге Башлыгыннан тыш, даими яки вакытлы комиссияләр төзелергә (яки) авыл җирлеге Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча аталган мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы депутатлар билгеләнергә мөмкин. Депутатлар икедән артмаган даими комиссияләрдә эшләргә хокуклы.

3. Муниципаль программаларны, авыл җирлеге Советы карарларын әзерләү, авыл җирлеге карамагына кертелгән бигрәк тә әһәмиятле мәсьәләләр турында фикер алышу өчен авыл җирлеге Советы каршында аның карары нигезендә депутатлар, авыл җирлеге Башкарма комитеты, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар һәм предприятиеләр вәкилләре, экспертлар һәм авыл җирлегендә яшәүчеләр составында эш, эксперт һәм бүтән төрле киңәшмә төркемнәре төзелергә мөмкин.

## 35 статья. Авыл җирлеге Советы тарафыннан контроль функцияләрне гамәлгә ашыру

1. Авыл җирлеге Советы тарафыннан авыл җирлеге территориясендә әлеге Устав нигезләмәләренең, авыл җирлеге Советы кабул итә торган норматив хокукый актларның үтәлешенә, авыл җирлеге бюджетының үтәлешенә, бюджетныкы булмаган фондлар акчасыннан файдалануга, авыл җирлеген үстерү программаларына, авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм аның Җитәкчесе эшчәнлегенә контрольлек гамәлгә ашырыла.

2. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан законнарны, әлеге Уставны һәм бүтән муниципаль норматив хокукый актларны бозу фактлары ачыкланган очракта авыл җирлеге Советы карары белән депутатлар арасыннан аталган фактларны тикшерү өчен вакытлыча контроль комиссияләре төзелергә мөмкин.

3. Законнар нигезендә авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча авыл җирлеге бюджеты акчаларының максатчан кулланылуына, муниципаль мөлкәттән файдалану нәтиҗәлелегенә тикшерүләр (ревизияләр) уздырылырга мөмкин. Аталган контроль һәм эксперт-аналитик чараларны уздыру тәртибе Авыл җирлегенең ревизия комиссиясе турында нигезләмәдә билгеләнә.

4. Авыл җирлеге Башкарма комитеты, аның Җитәкчесе, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, вазыйфаи затлар, территориаль иҗтимагый үзидарә

органнары, әгәр законда башкасы билгеләнмәсә, авыл җирлеге Советы, аның контроль комиссияләре, авыл җирлеге Советы депутаты мөрәҗәгате буенча авыл җирлеге Советы карамагына карый торган мәсьәләләр буенча сорала торган мәгълүматны бирергә, ә законнарны, муниципаль норматив хокукый актларны бозуга күрсәтелгәндә, хокук бозуларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

5. Авыл җирлеге Советы, контроль функцияләрне гамәлгә ашырып, авыл җирлеге Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм үтәү-боеру эшчәнлегенә тыкшынырга хокуклы түгел.

## 36 статья. Азнакай муниципаль районы Советына авыл җирлеге вәкилен сайлау

1. Азнакай муниципаль районы Советына авыл җирлегеннән вәкил авыл җирлеге Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән сайлап куела.

2. Авыл җирлеге Советына билгеләнгән депутатлар арасыннан яртысыннан артыгы аның өчен тавыш биргән кандидат – сайланган булып санала.

## 37 статья. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) үзлектән тарату турында авыл җирлеге Советы карары кабул ителү нигезендә;

2) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясында каралган тәртиптә һәм нигезләрдә авыл җирлеге Советы таратылганда;

3) авыл җирлеге Советының әлеге депутатлары составының хокуксыз булуы турында, шул исәптән депутатларның үз вәкаләтләрен калдыруына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Югары суды карары үз көченә кергәндә;

4) авыл җирлеге үзгәртеп корылганда, шулай ук авыл җирлеге бетерелгән очракта;

5) шәһәр округы белән берләштерелүенә бәйле рәвештә, авыл җирлегенең муниципаль берәмлек статусы юкка чыкканда;

6) авыл җирлеге чикләрен үзгәртүгә яки авыл җирлеген шәһәр округы белән берләштерүгә бәйле рәвештә авыл җирлегендәге сайлаучыларның саны 25 проценттан күбрәк артып киткәндә;

7) гражданнар тарафыннан турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны үтәү өчен таләп ителә торган хокукый актны чыгару срогы бозылганда.

2. Авыл җирлеге Советының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату андагы депутатларның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга китерә.

3. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта авыл җирлегенең Сайлау комиссиясе авыл җирлеге Советына вакытыннан алда

депутатлар сайлауны билгели, алар авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан ул туктатылган көннән башлап алты айдан да соңга калмыйча уздырыла.

### 38 статья. Авыл җирлеге Советын үзлектән тарату турында карар кабул итү тәртибе

1. Авыл җирлеге Советын үзлектән тарату турында карар авыл җирлеге Башлыгы яки авыл җирлеге Советына билгеләнгән депутатлар арасыннан кимендә яртысын тәшкил иткән депутатлар төркеме инициативасы буенча кабул ителергә мөмкин.

2. Үзлектән тарату турында карар кабул итү инициативасы чыгарыла алмый:

1) авыл җирлеге Советы сайланганнан соң беренче ел эчендә;

2) авыл җирлеге бюджетын кабул итү һәм аның үтәлеше турында хисап раслау чорында;

3) авыл җирлеге Башлыгын чакыртып алу турында тавыш бирүне уздыру чорында яисә аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта.

3. Авыл җирлеге Советын үзлектән тарату турында язмача тәкъдимдә үзлектән таратуның нигезләре булырга тиеш, шулай ук аңа үзлектән тарату сәбәпләрен нигезләүче бүтән материаллар да теркәлергә мөмкин.

4. Үзлектән тарату турында мәсьәләне алдан карау өчен авыл җирлеге Советы карары белән депутатлар арасыннан комиссия төзелә. Авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге Башлыгы карары нигезендә авыл җирлеге Советын үзлектән тарату турында мәсьәлә гавами тыңлауларга чыгарылырга мөмкин.

5. Авыл җирлеге Советын үзлектән тарату турында мәсьәләне карау озынлыгы авыл җирлеге Советы депутатлары һәм авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан үзлектән тарату инициативасының барлык шартлары һәм нигезләре турында төрле яклап һәм объектив рәвештә фикер алышу мөмкинлеген гарантияләрлек булырга тиеш. Үзлектән тарату турында карар үзлектән тарату турында инициатива чыгарылган көннән башлап ике ай узгач кабул ителергә мөмкин.

6. Авыл җирлеге Советын үзлектән тарату турында карар яшерен тавыш бирү юлы белән авыл җирлеге Советына билгеләнгән депутатлар арасыннан өчтән икесенең тавышлары нигезендә кабул ителә.

7. Авыл җирлеге Советы үзлектән тарату турында тәкъдимне кире каккан очракта, үзлектән тарату турында яңа инициатива үзлектән тарату турында мәсьәлә буенча тавыш биргән көннән башлап кимендә бер елдан соң гына чыгарылырга мөмкин.

### 39 статья. Авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) вафат булганда;

2) үз теләге белән отставкага киткәндә;

3) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки чикләнгән рәвештә эшкә яраклы дип танылганда;

4) суд тарафыннан билгесез югалган дип танылганда яки вафат булган дип игълан ителгәндә;

5) үзенә карата гаепләүле суд карары законлы көченә кергәндә;

6) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына чыгып киткәндә;

7) Россия Федерациясе гражданлыгы беткәндә, чит ил гражданинына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил дәүләте гражданлыгы беткәндә, аның тарафыннан чит ил гражданлыгы алынганда яки аның тарафыннан чит илдә яшәүгә рөхсәт яки чит ил дәүләте гражданлыгына ия булган Россия Федерациясе гражданинына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы булып тормаган чит ил дәүләте территориясендә Россия Федерациясе гражданинының даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ алынганда;

8) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алынганда;

9) авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда;

10) хәрби хезмәткә чакырылганда яки аны алмаштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә юлланганда;

11) федераль законнарда билгеләнгән бүтән очракларда.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1-7, 10 һәм 11 пунктларда күрсәтелгән очракларда авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен туктату турында карар авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә, анда авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләре туктатылган көн билгеләнә.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 8 пунктында каралган очракта, авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән туктатыла.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 9 пунктында каралган очракта, авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләре авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктаган көннән башлап туктатыла.

5. Авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, депутатны өстәмә сайлау федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә билгеләнә.

6. Авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында авыл җирлеге Советы карары вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигезләр барлыкка килгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча кабул ителә, ә әгәр бу нигез авыл җирлеге Советы утырышлары арасындагы чорда барлыкка килсә, – мондый нигез барлыкка килгән көннән башлап өч айдан соңга калмыйча.

7. Татарстан Республикасы Президенты авыл җирлеге депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн булып авыл җирлеге Советына әлеге гариза килгән көн санала.

# IV БҮЛЕК. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## 40 статья. Авыл җирлеге Башлыгы – авыл җирлегенең иң югары вазыйфаи заты

1. Авыл җирлеге башлыгы авыл җирлегенең иң югары вазыйфаи заты булып тора.

2. Авыл җирлеге Башлыгы авыл җирлеге Советы тарафыннан сайлана.

3. Авыл җирлеге Башлыгы бер үк вакытта авыл җирлеге Советына да һәм авыл җирлеге Башкарма комитетына да җитәкчелек итә.

4. Авыл җирлеге Башлыгы вазыйфасының рәсми исеме – Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы (Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы).

5. Авыл җирлеге Башлыгы вазыйфасы буенча Азнакай муниципаль районы Советы депутаты булып тора.

## 41 статья. Авыл җирлеге Башлыгын сайлау тәртибе

1. Авыл җирлеге Башлыгы яңа сайланган авыл җирлеге Советының беренче утырышында авыл җирлеге Советы депутатлары арасыннан, әгәр авыл җирлеге Советы тавыш бирүнең бүтән тәртибен билгеләмәсә, яшерен тавыш бирү юлы белән авыл җирлеге Советы вәкаләтләре срогына сайлана.

Авыл җирлеге Башлыгын сайлау авыл җирлеге Советы депутатлары тарафыннан күрсәтелә торган кандидатлар арасыннан, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүчеләрнең, иҗтимагый берләшмәләрнең, Татарстан Республикасы Президентының тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Авыл җирлеге Советы депутаты, әгәр аны сайлау өчен авыл җирлеге Советына билгеләнгән депутатлар арасыннан яртысыннан артыграгы тавыш биргән булса, авыл җирлеге Башлыгы булып сайланган була.

3. Сайланганнан соң авыл җирлеге Башлыгы түбәндәгечә ант китерә:

«Муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кереп, муниципаль берәмлек Уставында миңа тапшырылган үз вәкаләтләремне гамәлгә ашырганда, хәзерге һәм киләчәк буыннар каршында безнең муниципаль берәмлек өчен җаваплы булуны аңлап, Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын, Муниципаль берәмлек уставын катгый үтәргә, муниципаль берәмлек халкының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итәргә, сакларга һәм якларга, тарихи гореф-гадәтләрне ихтирам итеп, граждани ризалыкка һәм икътисадый потенциалны арттыруга омтылырга, муниципаль берәмлекне чәчәк аттыру максатында һәм андагы барча яшәүчеләр иминлеге өчен үз вазыйфаларымны гадел, намуслы итеп башкарырга ант итәм».

## 42 статья. Авыл җирлеге Башлыгы статусы

1. Авыл җирлеге Башлыгы даими нигездә эшли.

2. Авыл җирлеге Башлыгы Азнакай муниципаль районы Советында даими нигездә биләнә торган вазыйфага сайланган очракта, ул авыл җирлеге Башлыгы вәкаләтләрен азат ителмәгән нигездә гамәлгә ашыра.

3. Авыл җирлеге Башлыгы үзенең эшчәнлегендә авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм авыл җирлеге Советы каршысында федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә контрольдә тора һәм хисап тота.

4. Авыл җирлеге Башлыгы авыл җирлеге Советына үзенең эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында, ә авыл җирлеге башлыгы җирле хакимиятне җитәкләгән очракта, җирле хакимият һәм аның ведомство буйсынуында торган бүтән җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында, шул исәптән авыл җирлегенең вәкиллекле органы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү турында ел саен хисаплар тапшыра.

5. Авыл җирлеге Башлыгы «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләмәләрне, тыюларны сакларга, бурычларны үтәргә тиеш.

## 43 статья. Авыл җирлеге Башлыгының вәкаләтләре

Авыл җирлеге Башлыгы:

1) җирле үзидарә органнары белән башка муниципаль берәмлекләр, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән ике арадагы мөнәсәбәтләрдә авыл җирлеген күрсәтә, ышанычнамәдән башка авыл җирлеге исеменнән эш йөртә;

2) авыл җирлеге Советы эшен оештыра, авыл җирлеге Советы утырышларын чакырта һәм аларга рәислек итә;

3) әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә авыл җирлеге Советы кабул иткән норматив хокукый актларны, шулай ук авыл җирлеге Советы утырышы беркетмәләрен имзалый һәм халыкка белдерә;

4) авыл җирлеге Советы эшендә ачык булуны тәэмин итү һәм җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу буенча чаралар күрә һәм авыл җирлеге Советы эшчәнлеге турында халыкка даими рәвештә мәгълүмат җиткерә;

5) авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында гражданнарны кабул итүне оештыра, атнага бер мәртәбәдән ешрак булмаган күләмдә гражданнарны шәхсән кабул итә, гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;

6) авыл җирлеге акчалары белән, шул исәптән авыл җирлеге Советын тоту һәм эшчәнлеген тәэмин итүгә акчалар белән авыл җирлегенең расланган бюджеты

нигезендә эш итә, банк учреждениеләрендә авыл җирлегенең бюджет һәм башка төрле счетларын ача һәм яба;

7) закон һәм әлеге Устав нигезендә гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карар үтәлеше буенча авыл җирлеге Советының хокукый акты кабул ителүен оештыра;

8) авыл җирлеге бюджеты проектын һәм аны үтәү турындагы хисапларны авыл җирлеге Советына карау өчен тапшыра;

9) авыл җирлеген комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары проектларын һәм аларны үтәү турындагы хисапларны карау өчен авыл җирлеге Советына тапшыра;

10) авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасы проектын карау өчен авыл җирлеге Советына кертә, расланган структура нигезендә авыл җирлеге Башкарма комитетының билгеләнгән чик дәрәҗәдәге хезмәткәрләр исәбе һәм хезмәткә түләү фонды белән штат расписаниесен раслый;

11) муниципаль хезмәткәрләрне һәм авыл җирлеге Башкарма комитетындагы бүтән хезмәткәрләрне вазыйфаларына билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата бүләкләү һәм дисциплинар җаваплылык чараларын күрә;

12) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра һәм (яки) аларның авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырылуын тәэмин итә, аларның үтәлеше өчен шәхси җаваплы була; законнар нигезендә һәм аларны үтәү максатында тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара;

13) авыл җирлеге Советына үзенең эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында, авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм аның буйсынуында торучы башка җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән авыл җирлеге Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында ел саен хисаплар тапшыра;

14) дәүләт һәм бүтән органнарда авыл җирлеге мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар күрә, авыл җирлеге Башкарма комитеты исеменнән судка гаризалар тапшыра, ышанычнамәләр бирә;

15) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында авыл җирлекләре башлыклары карамагына кертелгән бүтән вәкаләтләрне, шулай ук әлеге Уставта, авыл җирлеге Советы карарларында авыл җирлеге Башлыгы компетенциясенә кертелгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

16) Муниципаль берәмлек Башлыгы «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләмәләрне һәм тыюларны үтәргә һәм вазыйфаларны башкарырга тиеш.

Авыл җирлеге Башлыгы булмый торган очракта һәм (яки) аңа үз вәкаләтләрен үтәү мөмкинлеге булмаганда, авыл җирлеге Советы карары нигезендә аның вазыйфалары авыл җирлеге Советы депутатларының берсенә йөкләнергә мөмкин.

## 44 статья. Авыл җирлеге Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Авыл җирлеге Башлыгының вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) вафат булганда;

2) үз теләге белән отставкага киткәндә;

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74.1 статьясы нигезендә отставкага киткәндә;

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфасыннан ваз кичкәндә;

5) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки чикләнгән рәвештә эшкә яраклы дип танылганда;

6) суд тарафыннан билгесез югалган дип танылганда яки вафат булган дип игълан ителгәндә;

7) үзенә карата гаепләүле суд карары законлы көченә кергәндә;

8) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына чыгып киткәндә;

9) Россия Федерациясе гражданлыгы беткәндә, чит ил гражданинына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил дәүләте гражданлыгы беткәндә, аның тарафыннан чит ил гражданлыгы алынганда яки аның тарафыннан чит илдә яшәүгә рөхсәт яки чит ил дәүләте гражданлыгына ия булган Россия Федерациясе гражданинына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы булып тормаган чит ил дәүләте территориясендә Россия Федерациясе гражданинының даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ алынганда;

10) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алынганда;

11) сәламәтлек торышы буенча авыл җирлеге Башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен суд тәртибендә билгеләнгән тотрыклы рәвештә хезмәткә сәләтле булмавы нигезендә;

12) авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда;

13) федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган авыл җирлеге үзгәртеп корылганда, шулай ук авыл җирлеге бетерелгән очракта;

14) шәһәр округы белән берләштерелүенә бәйле рәвештә, авыл җирлегенең муниципаль берәмлек статусы юкка чыкканда;

15) муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртүгә яки авыл җирлеген шәһәр округы белән берләштерүгә бәйле рәвештә авыл җирлегендәге сайлаучыларның саны 25 проценттан күбрәк артып киткәндә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1-10 пунктларда күрсәтелгән нигезләрдә авыл җирлеге Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, авыл җирлеге Советының иң якын утырышында яңа авыл җирлеге Башлыгы сайлана.

3. Әгәр авыл җирлеге Башлыгы вәкаләтләре авыл җирлеге Советы вәкаләтләре тәмамланырга алты айдан азрак вакыт калгач вакытыннан алда туктатылса, яңа авыл

җирлеге Башлыгын сайлау авыл җирлеге Советы карары буенча уздырылмаска мөмкин.

## V БҮЛЕК. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

### 45 статья. Авыл җирлеге Башкарма комитеты – авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үтәүче-боеручы органы

1. Авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үтәүче-боеручы органы булып тора.

2. Авыл җирлеге Башкарма комитетының рәсми исеме – «Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитеты».

3. Авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлеге Советы һәм авыл җирлегендә яшәүчеләр алдында хисап тота һәм контрольдә тора.

4. Авыл җирлеге Башкарма комитетының үз исеме белән мөһере, бланклары була.

5. Авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнар классификациясенә туры китереп, авыл җирлеге бюджетында аерым юлда карала.

### 46 статья. Авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасы

1. Башкарма комитетның структурасы авыл җирлеге Башлыгы күрсәтүе буенча авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана.

2. Авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасына авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатип), авыл җирлеге Башкарма комитетының бүтән вазыйфаи затлары керә.

### 47 статья. Башкарма комитетның вәкаләтләре

1. Башкарма комитет:

1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәпкә алу өлкәсендә:

– авыл җирлегенең бюджет проектын, авыл җирлеген комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары проектларын эшли;

– авыл җирлеге бюджеты үтәлешен тәэмин итә, авыл җирлеген комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары үтәлүен оештыра;

– авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында хисап, авыл җирлеген комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары үтәлүе турында хисаплар әзерли;

– авыл җирлегенең икътисадый торышын һәм социаль өлкәсен сыйфатлый торган статистика күрсәткечләре җыелуын һәм аталган белешмәләрнең законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшырылуын оештыра;

2) муниципаль мөлкәт белән идарә итү, авыл җирлеге территориясендә предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

– авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтендә торучы мөлкәт белән идарә итә, муниципаль мөлкәт объектларын булдыру, сатып алу, файдалану, алар белән эш итү һәм аларның арендасы турындагы мәсьәләләрне хәл итә;

– авыл җирлеге Советы карарында билгеләнгән очракларда, муниципаль мөлкәтне читләштерү турында, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында, тәкъдимнәрне авыл җирлеге Советына килештерү (раслау) өчен әзерли һәм кертә;

– муниципаль мөлкәттә тормаучы предприятиеләр, оешмалар белән авыл җирлеген икътисадый һәм социаль үстерүдә хезмәттәшлек итү турында шартнамәләр төзи; авыл җирлеге территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милекчелек формаларындагы предприятиеләрне булдыруга ярдәм итә;

– авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль казна учреждениеләре булдыра, аларның максатларын, эшчәнлек шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, муниципаль учреждениеләрне финанслауны тәэмин итә, муниципаль учреждениеләрне һәм предприятиеләрне үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итә, контракт нигезендә аларга җитәкчеләрне билгели һәм биләгән вазыйфаларыннан азат итә;

– муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыра; авыл җирлеген төзекләндерү, халыкка коммуналь хезмәт күрсәтү, социаль инфраструктура объектларын төзү һәм төзәтү, халыкның көнкүреш һәм социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле булган продукцияне җитештерү, хезмәтләр күрсәтү эшләренең, моның өчен каралган авыл җирлегенең шәхси матди һәм финанс чараларыннан файдаланып башка эшләрне башкаруга заказчы сыйфатында чыгыш ясый;

– авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә булышлык күрсәтә, кече һәм урта эшкуарлык өчен шартлар тудыра;

– авыл җирлеге музейларын булдыра;

3) территориаль планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә табигать тирәлеген саклау өлкәсендә:

– муниципаль мөлкәттә торучы җирләрне планлаштыруны һәм алардан рациональ файдалануны һәм аларны саклауны оештыруны гамәлгә ашыра;

– авыл җирлеге чикләрендә җирләрне резервка куюны һәм җир кишәрлекләрен муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алуны гамәлгә ашыра;

– халыкка экологик вәзгыять турында мәгълүмат ирештерә, әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудыручы, табигатьтән файдалану турында законнарны бозучы предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның гамәлләре турында тиешле органнарга хәбәр итә;

4) төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә:

– билгеләнгән тәртиптә гражданнарның социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар сыйфатында исәбен алып бара;

– билгеләнгән тәртиптә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү турында карарлар кабул итә, торак урыннарны үзгәртеп коруны һәм үзгәртеп планлаштыруны килештерә, билгеләнгән тәртиптә муниципаль торак фондындагы торак урыннарны яшәү өчен яраксыз дип таный;

– авыл җирлегенең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү, авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү, авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшли һәм гамәлгә ашыра, аларга карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;

5) торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм халыкка башка төрле хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

– халыкны элемтә хезмәтләре, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудырылуын тәэмин итә;

– халыкның ялын оештыру һәм аларны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

– туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

– муниципаль янгын сагы эшен оештыра;

– авыл җирлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыра һәм гамәлгә ашыра;

– авыл җирлегендә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләрне башкара;

– авыл җирлеге территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

– Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм авыл җирлеге территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтә;

– каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аралап җыю) һәм транспорт белән күчерү буенча эшчәнлекне оештыруда катнаша;

– авыл җирлеге чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су агызуны, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыра;

– авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыра;

– милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) каршылыкларны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

– авыл җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм, гражданнарның уртак файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керә алуын тәэмин итүне дә кертеп, халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыра;

6) төзекләндерү өлкәсендә:

– авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне һәм яшелләндерүне оештыра;

– урамнарны яктыртуны һәм урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштырылуны тәэмин итә;

– кече архитектура формаларын урнаштыра һәм карап тота;

– йола буенча үткәрелә торган хезмәтләр күрсәтүне һәм җирләү урыннарын карап тотуны оештыра;

7) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә:

– авыл җирлеге өлкәсендә законнарның, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары актлары үтәлүен, гражданнарның хокуклары һәм ирекләре саклануын тәэмин итә;

– билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судында дәүләт хакимияте органнарының һәм дәүләт вазыйфаи затларының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның җирле үзидарә хокукын боза торган актларына шикаять белдерә;

– авыл җирлегендәге торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чаралар уздырылуын тәэмин итә;

– авыл җирлеге территориясендә булган муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең мобилизацияле әзерлеге буенча чараларны оештыра һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

– опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруда катнаша;

– муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирүне, авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

– авыл җирлеге территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү, рәсми физик культура-савыктыру һәм авыл җирлеге спорт чараларын уздыруны оештыру өчен шартлар тәэмин итә;

– җәмәгатьчелек тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә булышлык күрсәтә, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыра;

– кеше хокукларын тәэмин итүне иҗтимагый тикшереп торуны һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм итә һәм инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм күрсәтә;

– «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыра;

– инвалидларның, сәламәтлеге буенча мөмкинлеге чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм итә;

8) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

– федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

– дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди һәм финанс чараларының исәбен алып бара һәм аларның тиешенчә файдаланылуын тәэмин итә;

– тиешле федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра;

– авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә, үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары карамагында торган матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалануны тәэмин итә;

9) бүтән вәкаләтләр:

– авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыруны, хокукый, мәгълүмати, матди-техник яктан һәм башкача тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

– авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыруны гамәлгә ашыра;

– үз вәкаләтләре кысаларында федераль законнарга туры китереп халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра;

– авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү максатларында авыл җирлеге өчен социаль әһәмиятле булган эшләрне (шул исәптән кизү торуларны) ирекле нигездә башкару өчен гражданнарны җәлеп итү турында карарлар кабул итә һәм аларның уздырылуын оештыра;

– муниципаль хезмәтләр реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен билгели;

– законнарда, әлеге Уставта, авыл җирлеге Советы карарларында авыл җирлеге компетенциясенә яки авыл җирлеге җирле үзидарәсенең бүтән органнарына кертелгән вәкаләтләрдән тыш, авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Башкарма комитет, законнарда, әлеге Уставта, авыл җирлеге Советы карарларында авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән вәкаләтләрдән тыш, авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча бүтән вәкаләтләрне дә гамәлгә ашыра.

## VI БҮЛЕК. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАННАРЫ. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ҮЗАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ

### 48 статья. Авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе

1. Авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе даими эшли торган, җирле үзидарәнең финанс контроле буенча коллегиаль органы булып тора.

2. Авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе рәистән һәм кимендә ике әгъзадан тора.

3. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлар вазыйфасына кандидатураларны карау тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый акты яки регламенты белән билгеләнә.

4. Авыл җирлегенең контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлар вазыйфасына югары белеме һәм дәүләт, муниципаль идарә, дәүләт, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанслар, юриспруденция өлкәсендә эш тәҗрибәсе булган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнә.

5. Авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе түбәндәге төп вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) җирле бюджет үтәлешен тикшерү;

2) җирле бюджет проектларына экспертиза;

3) җирле бюджетны үтәү турында еллык хисапка тышкы тикшерү;

4) җирле бюджет акчаларыннан, шулай ук җирле бюджетка Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән чыганаклардан алына торган акчалардан файдалануның законлы, нәтиҗәле (файдалы һәм экономияле) булуына контроль оештыру һәм гамәлгә ашыру;

5) муниципаль мөлкәттә торучы мөлкәт белән, шул исәптән саклана торган интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм муниципаль берәмлеккә караган индивидуальләштерү чаралары белән идарә һәм эш итүнең билгеләнгән тәртибе үтәлүен тикшерү;

6) җирле бюджет хисабына салым һәм башка төрле ташламаларны һәм өстенлекләрне, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук җирле бюджет һәм муниципаль мөлкәттә торучы мөлкәт хисабына юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан кылына торган алыш-бирешләр буенча муниципаль гарантияләр бирүнең һәм үз өстенә алынган җаваплылыкларның яки йөкләмәләрнең башка ысуллар белән үтәлүен тәэмин итүнең законлы булу-булмавын бәяләү;

7) муниципаль берәмлек йөкләмәләренең, шулай ук муниципаль программаларның чыгымнарына кагылган өлештә муниципаль хокукый актларның проектларына финанс-икътисадый экспертиза (финанс-икътисадый нигезләүләрнең нигезле булу-булмавын да кертеп);

8) муниципаль берәмлектә бюджет процессына анализ һәм аны камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәрне әзерләү;

9) җирле бюджет үтәлеше барышы турында, уздырылган контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерләү һәм мондый мәгълүматны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына һәм муниципаль берәмлек башлыгына бирү;

10) вәкаләтләр чигендә коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларда катнашу;

11) тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендә федераль законнарда, Россия Федерациясе субъекты законнарында, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы уставында һәм норматив хокукый актларында билгеләнгән бүтән вәкаләтләр.

## 49 статья. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек итү һәм бәхәсләрне хәл итү нигезләре

1. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлек итү тәртибе авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларында билгеләнә.

2. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары арасында үзләренең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча бәхәсләр килештерү процедураларын уздыру юлы белән яки суд тәртибендә хәл ителә.

## VII БҮЛЕК. САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

### 50 статья. Авыл җирлегенең Сайлау комиссиясе

1. Авыл җирлеге Сайлау комиссиясе федераль законнарда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә формалаштырыла.

Сайлау комиссиясе 67-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясының 2 пунктында, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәр, шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәләренең, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрнең, шулай ук «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатларын сайлау турында» Федераль законның 82.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрнең һәм авыл җирлегенең вәкиллекле органында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәләренең тәкъдимнәре нигезендә формалаша.

2. Авыл җирлеге Советы авыл җирлегенең сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми исәбеннән яртысын түбәндәгеләрдән килгән тәкъдимнәр нигезендә билгеләргә бурычлы:

1) Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрнең, шулай ук «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатларын сайлау турында» Федераль законның 82.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрнең;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партияләрнең, шулай ук Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 97.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партияләрнең.

3. Авыл җирлеге Советы муниципаль районның сайлау комиссиясеннән, территориаль сайлау комиссиясеннән, территориаль сайлау комиссиясеннән алынган тәкъдимнәр нигезендә авыл җирлегенең сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми исәбендә яртысын түбәндәге тәртиптә билгеләп куярга тиеш:

1) әгәр муниципаль районның сайлау комиссиясе вәкаләтләре территориаль сайлау комиссиясенә йөкләнмәгән булса, авыл җирлеге сайлау комиссиясенең ике әгъзасы муниципаль районның сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә билгеләп куела, авыл җирлеге сайлау комиссиясенең калган әгъзалары территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә билгеләп куела;

2) әгәр муниципаль районның сайлау комиссиясе вәкаләтләре территориаль сайлау комиссиясенә йөкләнгән булса, авыл җирлегенең сайлау комиссиясе әгъзалары территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә билгеләп куела;

3) әгәр территориаль сайлау комиссиясе вәкаләтләре муниципаль районның сайлау комиссиясенә йөкләнгән булса, авыл җирлеге сайлау комиссиясе әгъзалары муниципаль районның сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә билгеләп куела.

4. Авыл җирлеге сайлау комиссиясенең вәкаләтләр срогы 5 ел тәшкил итә.

5. Авыл җирлегенең сайлау комиссиясе хәл иткеч тавыш хокукы белән 6 әгъза күләмендә формалаша.

6. Россия Федерациясе субъекты законы, авыл җирлеге уставы нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе була.

7. Авыл җирлегенең сайлау комиссиясе муниципаль орган булып тора һәм җирле үзидарә органнары структурасына керми.

8. Авыл җирлеге сайлау комиссиясе муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, депутатны, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирүне, авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүләрне әзерләүне һәм уздыруны оештыра.

6. Авыл җирлеге сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанс яктан тәэмин итү Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнар классификациясенә туры китереп, авыл җирлеге бюджетында аерым юлда карала.

7. Авыл җирлеге сайлау комиссиясенең вәкаләтләре, аның эшчәнлегенең тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җайга салына. Авыл җирлеге сайлау комиссиясенең вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең авыл җирлеге Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән карары нигезендә территориаль сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.

## VIII БҮЛЕК. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ГРАЖДАНИ-ХОКУКЫЙ ҺӘМ ФИНАНС НИГЕЗЛӘРЕ

### 51 статья. Авыл җирлегенең юридик зат хокукларына ия булган җирле үзидарә органнары

Федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә авыл җирлеге Башкарма комитетына юридик зат хокуклары бирелә.

### 52 статья. Авыл җирлегенең юридик зат буларак җирле үзидарә органнары

1. Авыл җирлеге Башлыгы авыл җирлеге исеменнән мөлкәти һәм бүтән төрле хокукларны һәм йөкләмәләрне сатып алырга һәм гамәлгә ашырырга, судта ышанычнамәдән башка чыгыш ясарга мөмкин.

2. Авыл җирлегенең Башкарма комитеты идарәи вазыйфаларны гамәлгә ашыру өчен төзелә торган муниципаль казна учреждениесе булып тора һәм федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

### 53 статья. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарын финанслау

Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген финанс яктан тәэмин итү фәкать авыл җирлеге бюджетының үз керемнәре хисабыннан гына гамәлгә ашырыла.

## IX БҮЛЕК. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫНА ҺӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БҮТӘН ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНА БИРЕЛӘ ТОРГАН СОЦИАЛЬ ҺӘМ БҮТӘН ТӨРЛЕ ГАРАНТИЯЛӘР

### 54 статья. Авыл җирлеге Башлыгына һәм авыл җирлегенең бүтән вазыйфаи затларына бирелә торган социаль һәм бүтән төрле гарантияләр

Авыл җирлеге Башлыгының һәм авыл җирлегенең бүтән вазыйфаи затларының социаль һәм бүтән төрле гарантияләре «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә билгеләнә.

## X БҮЛЕК. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

### 55 статья. Җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының җаваплылыгы

Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары авыл җирлеге халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар каршысында законнар нигезендә җаваплы була.

### 56 статья. Авыл җирлегендә яшәүчеләр алдында авыл җирлеге Советы депутатларының җаваплылыгы

1. Авыл җирлеге Советы депутатларының, шул исәптән авыл җирлеге Башлыгының, авыл җирлегендә яшәүчеләр алдында җаваплылыгы авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан сайланган тиешле депутатка ышаныч югалту нәтиҗәсендә барлыкка килә.

2. Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең ышанычын югалткан авыл җирлеге Советы депутаты, шул исәптән авыл җирлеге Башлыгы, әлеге Уставта каралган нигезләрдә һәм тәртиптә чакыртып алынырга мөмкин.

### 57 статья. Җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының дәүләт каршысындагы җаваплылыгы

1. Федераль законнар нигезендә авыл җирлеге Советының, авыл җирлеге Башлыгының, Башкарма комитет Җитәкчесенең дәүләт каршысындагы җаваплылыгы алар тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституция законнары, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Устав бозылган очракта, шулай ук авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашырмаган очракта тиешле суд карары нигезендә барлыкка килә.

2. Авыл җирлеге Советын тарату, авыл җирлеге Башлыгын, авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесен вазыйфасыннан алу һәм отставкага җибәрү нигезләре һәм тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнә.

### 58 статья. Җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының физик һәм юридик затлар алдында җаваплылыгы

Җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының физик һәм юридик затлар алдында җаваплылыгы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә барлыкка килә.

## XI БҮЛЕК. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫ

### 59 статья. Авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлары системасы

1. Авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлары системасына түбәндәгеләр керә:

1) авыл җирлеге Уставы, җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар;

2) авыл җирлеге Советының норматив һәм бүтән хокукый актлары;

3) авыл җирлеге Башлыгының, Башкарма комитетның һәм җирле үзидарәнең бүтән органнарының һәм вазыйфаи затларының әлеге Уставта каралган хокукый актлары.

Норматив холыкка ия булмаган муниципаль хокукый актның гамәлдә булуы, Россия Федерациясе Президенты каршында Эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән тиешле күрсәтмәсе алынган очракта, аны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органы яки җирле үзидарәнең вазыйфаи заты тарафыннан кичекмәстән туктатыла. Алынган күрсәтмәне үтәү турында җирле үзидарәнең үтәүче-боеручы органнары яки җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Президенты каршында Эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә өч көнлек срокта, ә

җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарына алар тарафыннан карар кабул ителгән көннән башлап өч көннән соңга калмыйча хәбәр итәргә бурычлы.

2. Авыл җирлеге Уставы һәм хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән, җирле референдумда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар системасында иң югары юридик көчкә ия актлар булып тора, турыдан-туры гамәлдә була һәм авыл җирлегенең барча территориясендә кулланыла.

Бүтән муниципаль хокукый актлар әлеге Уставка һәм җирле референдумда кабул ителгән хокукый актларга каршы килергә тиеш түгел.

3. Муниципаль хокукый актлар тиешле муниципаль хокукый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары яки җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлдән чыгарылырга яки аларның гамәлдә булуы туктатып торылырга мөмкин, мондый органнар яки тиешле вазыйфалар бетерелгән яки күрсәтелгән органнарның яки вазыйфаи затларның исемлегенә үзгәрешләр кертелгән очракта, – гамәлдән чыгару яки гамәлдә булуын туктатып тору вакытына тиешле муниципаль хокукый актны кабул итү (чыгару) вәкаләте бирелгән җирле үзидарә органнары яки җирле үзидарә вазыйфаи затлары, шулай ук суд тарафыннан; ә җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга салу өлешендә, – Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы (Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле дәүләт органы) тарафыннан.

4. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар авыл җирлегенең барча территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиешле, муниципаль хокукый актларны үтәмәгән өчен гражданнар, оешмаларның җитәкчеләре, дәүләт хакимияте органнары вазыйфаи затлары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җаваплы була.

.

## 60 статья. Гражданнар тарафыннан турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарлар

1. Авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры хәл итү гражданнарның җирле референдумда турыдан-туры ихтыяр белдерүе юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль норматив хокукый актны кабул итү (чыгару) таләп ителсә, аталган актны кабул итүгә (чыгаруга) компетенцияле булган авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге Башлыгы рефрендумда кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән башлап 15 көн эчендә тиешле муниципаль норматив хокукый актны әзерләү һәм (яки) кабул итү срогын билгеләргә бурычлы. Күрсәтелгән чор өч айдан артык була алмый.

3. Гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль норматив хокукый актны чыгару срогын бозу авыл җирлеге Башлыгын чакыртып алу яки авыл җирлеге Советының вәкаләтләрен алдан туктату өчен нигез булып тора.

## 61 статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актларның төрләре

1. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү максатында түбәндәге муниципаль хокукый актларны чыгара:

1) авыл җирлеге Советы – авыл җирлеге Советы карарын;

2) авыл җирлеге Башлыгы – авыл җирлеге Башлыгы карарларын һәм күрсәтмәләрен.

2. Авыл җирлеге җирле үзидарәсенең бүтән вазыйфаи затлары үзләренең әлеге Уставта, аларның статусын билгели торган бүтән муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә күрсәтмәләр һәм боерыклар чыгара.

## 62 статья. Муниципаль хокукый актларны әзерләү

1. Муниципаль хокукый актларның проектлары авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Советы депутатлары, территориаль иҗтимагый үзидарә, гражданнарның инициатив төркемнәре, Азнакай шәһәре прокуроры, шулай ук авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе тарафыннан аның карамагында булган мәсьәләләр буенча кертелергә мөмкин.

2. Муниципаль хокукый актларның проектларын кертү тәртибе, аларга теркәлә торган документлар исемлеге һәм формасы тиешенчә авыл җирлеге Советы Регламентында һәм авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Норматив хокукый актларның проектлары аларны җирле үзидарә органнары һәм алардагы вазыйфаи затлар тарафыннан кабул иткән көннән башлап 10 көн эчендә коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Азнакай шәһәре прокуратурасына тапшырыла. Проектлар прокуратурага норматив хокукый актта коррупциячел факторларның булмавы турында тиешле норматив хокукый акт проектын әзерләгән вазыйфаи зат тарафыннан бирелгән бәяләмәне теркәп тапшырыла.

## 63 статья. Авыл җирлеге Советы хокукый актлары

1. Авыл җирлеге Советы федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Уставта үзенең компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча авыл җирлеге территориясендә үтәү өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне билгеләүче карарлар, авыл җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турында карар, шулай ук авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча һәм федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Уставта аның компетенциясенә кертелгән бүтән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.

2. Авыл җирлеге Советының авыл җирлеге территориясендә үтәү өчен мәҗбүри булган карарлары, әгәр федераль законнарда башкача билгеләнмәсә, авыл җирлеге Советына билгеләнгән депутатлар исәбендә күпчелек тавышлар белән кабул ителә.

3. Авыл җирлеге Советының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүне, үзгәртүне һәм гамәлдән чыгаруны, авыл җирлеге бюджеты акчаларыннан чыгымнар тотуны күздә тоткан карарлары авыл җирлеге Советына карау өчен фәкать авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча гына яки аның бәяләмәсе булганда гына кертелергә мөмкин. Аталган бәяләмә аның тарафыннан авыл җирлеге Советына авыл җирлеге Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә утыз көнлек срокта тапшырыла.

4. Авыл җирлеге Советы карарлары аларны кабул иткән көннән башлап өч көнлек срокта авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан имзалана һәм әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә аның тарафыннан халыкка белдерелә.

5. Авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты авыл җирлеге Башлыгы имзалаганнан соң 30 көн эчендә коррупциячел факторлары булмавы турында аның проектын әзерләгән вазыйфаи зат тарафыннан бирелгән бәяләмәне теркәп, коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Азнакай шәһәре прокуратурасына җибәрелә.

## 64 статья. Авыл җирлеге Башлыгы хокукый актлары

1. Авыл җирлеге Башлыгы үзенең законнарда, әлеге Уставта, авыл җирлеге Советы карарларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар һәм боерыклар, шулай ук авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре һәм федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча карарлар, шулай ук авыл җирлеге Башкарма комитеты эшен оештыру мәсьәләләре буенча боерыклар чыгара.

2. Авыл җирлеге Башлыгының норматив хокукый акты имзаланганнан соң 30 көн эчендә коррупциячел факторлары булмавы турында аның проектын әзерләгән вазыйфаи зат тарафыннан бирелгән бәяләмәне теркәп, коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Азнакай шәһәре прокуратурасына җибәрелә.

## 65 статья. Муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка белдерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе

1. Авыл җирлеге Советы карарлары, әгәр дә карарның үзендә башкача каралмаса, авыл җирлеге Башлыгы аларга имза куйган көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Авыл җирлеге Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Авыл җирлеге Уставын кабул итү яисә шушы Уставка үзгәрешләр кертү турында авыл җирлеге Советы карарлары федераль законда, шушы Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Авыл җирлеге Башлыгының, җирле үзидарәдәге бүтән вазыйфаи затларның хокукый актлары, актларның үзләрендә башкача каралмаса, аларга имза куелган көннән үз көченә керә.

3. Кешенең һәм гражданинның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган, гамәлгә куючысы буларак авыл җирлеге катнаша торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларны рәсми бастырып чыгаргач (халыкка белдергәч) үз көченә керә.

4. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары булырга тиеш: аталышы, имза куелу датасы (авыл җирлеге Советы кабул иткән хокукый актлар өчен – шулай ук авыл җирлеге Советы тарафыннан аның кабул ителү датасы), теркәлү номеры, хокукый актка имза куйган вазыйфаи затның исеме.

5. Авыл җирлеге бюджеты турында, аны үтәү хакында хисап турында, җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү турында авыл җирлеге Советы карарлары, авыл җирлеге Советы Регламенты, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан кабул ителгән бүтән норматив хокукый актлар аларга имза куелган көннән соңгы җиде көнлек чорда рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш, таратылуы федераль закон белән чикләнүче мәгълүматларны үз эченә алган муниципаль норматив хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш.

6. Муниципаль сайлаулар, җирле референдум билгеләү, авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу, авыл җирлегенең чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору, авыл җирлеге Башлыгын һәм аның урынбасарын сайлау мәсьәләсе буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы норматив булмаган хокукый актлар һәм башка төрле актлар законнар нигезендә шулай ук рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

7. Рәсми рәвештә бастырып чыгарылуы (халыкка белдерелүе) законнар яисә шушы Устав нигезендә зарури булмаган норматив булмаган муниципаль хокукый актлар аларны чыгарган органнарның яисә авыл җирлегендәге җирле үзидарә вазыйфаи затларының карары буенча бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) мөмкин.

8. Бастырып чыгарганда (халыкка белдергәндә) муниципаль хокукый актның реквизитлары күрсәтелә.

Муниципаль хокукый актларны рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка белдерү) түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

– хокукый актның текстын авыл җирлегендәге җирле үзидарә органнары гамәлгә куйган массакүләм басма мәгълүмат чараларында яисә авыл җирлеге территориясендә таратыла торган бүтән массакүләм басма мәгълүмат чараларында бастырып чыгару. Хокукый актның текстын бүтән массакүләм басма мәгълүмат чараларында бастырганда мондый рәвешле бастыруның рәсми булуы турында тамга булырга тиеш;

– үзәкләштерелгән тәртиптә хокукый акт текстын авыл җирлегендә яшәүчеләргә, шул исәптән махсус басма матбугат рәвешендә, тарату (биреп чыгу);

– хокукый актның текстын авыл җирлеге торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру; күрсәтелгән стендларның саны һәм аларны урнаштыру урыннары авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана һәм авыл җирлегендә яшәүчеләргә муниципаль хокукый актның тексты белән каршылыкларсыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш;

– хокукый акт текстын http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда урнаштыру;

– хокукый акт текстын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aznakaevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру.

9. Муниципаль хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка белдергәндә) басма массакүләм мәгълүмат чарасының чыгу датасы яки тиешле актны халыкка белдерү датасы турында белешмәләр күрсәтелергә тиеш, алар актны тарата (биреп чыга) башлау яки аны мәгълүмат стендында урнаштыру датасына туры килергә тиеш.

10. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарлар законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

11. Муниципаль норматив хокукый актлар түбәндәге нигезләрдә көчен югалткан һәм гамәлдә булуын туктаткан дип санала:

а) яңадан кабул ителгән муниципаль норматив хокукый акт текстында гамәлдән чыгару турында турыдан-туры күрсәтү нәтиҗәсендә;

б) элегрәк гамәлдә булган муниципаль норматив хокукый актны алмаштырган яңа муниципаль норматив хокукый акт кабул ителүгә бәйле рәвештә;

в) муниципаль норматив хокукый актның үзендә билгеләнгән гамәлдә булу срогы тәмамлангач.

## XII БҮЛЕК. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЕ

### 66 статья. Авыл җирлегенең икътисадый нигезе

Авыл җирлегенең икътисадый нигезен авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтендә торучы мөлкәт, авыл җирлеге бюджеты акчалары, шулай ук авыл җирлегенең мөлкәти хокуклары тәшкил итә.

### 67 статья. Авыл җирлегенең муниципаль мөлкәте

Авыл җирлеге мөлкәтендә түбәндәгеләр торырга мөмкин:

1) әлеге Уставның 6 статьясында билгеләнгән авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән очракларда җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук җирле үзидарә органнарының аларга «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешендә каралган тәртиптә тапшырылган аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) авыл җирлеге Советының норматив хокукый актлары нигезендә районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) федераль законнарда аларны хәл итү хокукы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт;

5) әлеге Уставның 7 статьясы нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 һәм 1.1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.

2. Авыл җирлегендә милекчелек хокукында әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килми торган мөлкәт барлыкка килгән очракларда, аталган мөлкәтнең профиле үзгәртелергә (мөлкәтнең максатчан билгеләнеше үзгәртелергә) яки ул читләштерелергә тиеш. Мондый мөлкәтне читләштерүнең тәртибе һәм сроклары федераль законда билгеләнә.

### 68 статья. Авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү

1. Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәткә авыл җирлеге исеменнән мөстәкыйль рәвештә ия була, аннан файдалана һәм аның белән эш итә.

2. Җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәтне физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм бүтән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча яки даими рәвештә файдалануга тапшырырга, федераль законнар нигезендә читләштерергә, бүтән төрле алыш-бирешләрне башкарырга хокуклы.

### 69 статья. Муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре

1. Муниципаль берәмлек җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль предприятиеләр һәм казна учреждениеләре булдырырга, хуҗалык, шул исәптән муниципаль, җәмгыятьләрен оештыруда катнашырга мөмкин. Муниципаль предприятиеләргә һәм казна учреждениеләренә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен вәкаләтле җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

2. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары авыл җирлеге исеменнән муниципаль казна учреждениеләре йөкләмәләре буенча субсидиар җавап бирә һәм

федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә аларның үтәлүен тәэмин итә.

### 70 статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль мөлкәттә тормаучы предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән мөнәсәбәте

Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль мөлкәттә тормаучы предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән, шул исәптән физик затлар белән мөнәсәбәте, әгәр законнарда башкасы билгеләнмәсә, шартнамә нигезендә төзелә.

## XIII БҮЛЕК. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ФИНАНС НИГЕЗЕ

### 71 статья. Авыл җирлеге бюджеты

1. Авыл җирлегенең үз бюджеты бар.

2. Авыл җирлеге бюджеты авыл җирлеге Советының муниципаль норматив хокукый акты формасында эшләнә һәм раслана.

3. Авыл җирлеге бюджетында авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелә торган керемнәр һәм җирле үзидарә органнарына аларга федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен бирелә торган, шулай ук күрсәтелгән керемнәр хисабына гамәлгә ашырыла торган субвенцияләр һәм авыл җирлеге бюджетының тиешле чыгымнары субвенцияләре аерым карала.

4. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында хисаплар тапшыра.

### 72 статья. Авыл җирлегендә бюджет процессы

1. Авыл җирлеге бюджетын формалаштыру, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен тикшерүдә тоту авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла. Авыл җирлеге бюджетын формалаштыру, раслау һәм үтәү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

2. Авыл җирлеге бюджеты проекты, авыл җирлеге бюджетын раслау турында авыл җирлеге Советы карары, аның үтәлеше турында еллык хисап, авыл җирлеге бюджетын үтәү барышы турында кварталлык һәм, аларны акчалата тотуга фактик чыгымнарны күрсәтеп, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең,

муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең исәбе турында белешмәләр рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

3. Җирле салымнар турында муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында авыл җирлеге Советы муниципаль норматив хокукый актлары, авыл җирлеге Советының бюджетка бәйле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган, Россия Федерациясе бюджет системасындагы бюджетларның керемнәре үзгәрүгә китерә торган, киләсе финанс елында һәм план чорында үз көченә керә торган муниципаль норматив хокукый актлары киләсе финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында карар проекты авыл җирлеге Советына кертелгән көннән башлап 10 көн узганчы кабул ителергә тиеш.

4. Авыл җирлеге бюджеты проекты өч еллык срокка (киләсе финанс елына һәм план чорына) төзелә һәм раслана.

5. Киләсе финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты проекты авыл җирлегенең чыгым йөкләмәләрен финанс яктан тәэмин итү максатларында авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерү фаразы нигезендә төзелә.

6. Авыл җирлеге бюджеты проекты авыл җирлеге Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм андагы таләпләрне саклап кабул ителә торган авыл җирлеге вәкиллекле органы муниципаль хокукый актлары нигезендә төзелә.

7. Киләсе финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясе Президентының Бюджет юлламасына;

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасына;

авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерү фаразына;

авыл җирлегенең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләренә;

муниципаль программаларга (муниципаль программаларның проектларына, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларына).

8. Киләсе финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты турында карарда бюджетның төп сыйфатламалары булырга тиеш, аларга бюджетның гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы законнарында, авыл җирлеге Советы карарларында (авыл җирлеге бюджеты турында карарлардан тыш) билгеләнгән бүтән күрсәткечләр.

9. Киләсе финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты турында карарда, әгәр Россия Федерациясе бюджет хаконнарында билгеләнмәгән булсалар, Россия Федерациясе бюджет системасындагы бюджетлар арасында керемнәрне бүлү нормативлары булырга тиеш.

10. Авыл җирлеге бюджеты турында карарда түбәндәгеләр раслана:

– авыл җирлеге бюджетында керемнәрнең баш администраторлары исемлеге;

– авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслауда чыганакларның баш администраторлары исемлеге;

– бюджет ассигнованиеләрен чыгым төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буйлап яки

чыгым төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программалы булмаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) һәм (яки) киләсе финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгым төрләренең максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программалы булмаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буйлап, шулай ук, Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы законында, авыл җирлеге Советының муниципаль хокукый актында тиешенчә билгеләнгән очракларда, бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буйлап бүленеше;

– киләсе финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

– гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

– киләсе финанс елында һәм план чорында башка бюджетлардан алына торган һәм (яки) Россия Федерациясе бюджет системасындагы башка бюджетларга бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;

– киләсе финанс елына һәм план чорына план чорының беренче елына авыл җирлеге бюджетында чыгымнарның гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә (Россия Федерациясе бюджет системасындагы башка бюджетлардан бюджетара трансфертлар хисабына каралган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча), план чорының икенче елына авыл җирлеге бюджетындагы чыгымнарның гомуми күләмендә кимендә 5 проценты күләмендә (Россия Федерациясе бюджет системасындагы башка бюджетлардан бюджетара трансфертлар хисабыннан каралган, максатчан билгеләнеше булган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча) авыл җирлеге бюджеты расланган очракта, шартлы рәвештә раслана торган (расланган) чыгымнарның гомуми күләме;

– киләсе финанс елына һәм план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары;

– киләсе финанс елыннан соң һәм план чорының һәр елы артыннан килүче елның 1 гыйнварына булган торышында, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югарыгы дәрәҗәсен күрсәтеп, муниципаль эчке бурычның югарыгы дәрәҗәсе;

– Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, авыл җирлеге муниципаль хокукый актларында тиешенчә билгеләнгән авыл җирлеге бюджетының бүтән күрсәткечләре.

11. Киләсе финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты турында карар проекты расланган бюджетның план чоры параметрларын үзгәртү һәм аларга бюджет проектының план чорындагы икенче елы параметрларын өстәү юлы белән раслана.

Киләсе финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты турында карар проекты план чорына расланган бюджет күрсәткечләрен тәгаенли һәм төзелә торган бюджетның план чорындагы икенче елы күрсәткечләрен раслый.

Авыл җирлегенең раслана торган бюджетында план чоры параметрларын тәгаенләштерү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) киләсе финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты турында карар проектын карау предметы булып торган күрсәткечләргә тәгаенләштерүләрне раслау;

2) авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының расланган ведомство структурасы күрсәткечләренә арттыруларны яки кыскартуларны раслау яки аңа өстәмә максатчан статьялар һәм (яки) авыл җирлеге бюджетының чыгым төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен кертү.

12. Киләсе финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты турында карар проекты белән берлектә авыл җирлеге Советына түбәндәгеләр тапшырыла:

– бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

– агымдагы финанс елының узган чорына авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерүнең беренчел йомгаклары һәм агымдагы финанс елына авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерүнең көтелгән йомгаклары;

– авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерү фаразы;

– киләсе финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге консолидацияләнгән бюджетының төп сыйфатламаларын (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы) фаразлау;

– авыл җирлеге бюджеты проектына аңлатма язуы;

– бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикаларның проектлары) һәм исәпләмәләре;

– киләсе финанс елы азагына һәм план чорындагы һәр ел азагына муниципаль бурычның югарыгы дәрәҗәсе;

– агымдагы финанс елына көтелгән бюджет үтәлешен бәяләү;

– авыл җирлеге Советы, суд системасы органнары, авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән аталган органнарның бюджет сметалары проектлары, күрсәтелгән бюджет сметаларына карата авыл җирлеге Башкарма комитеты белән аңлашылмаучанлыклар килеп туган очракта тапшырыла;

– Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, әлеге Уставта, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән документлар һәм материаллар.

Авыл җирлеге бюджеты турында карарда муниципаль программалар һәм программалы булмаган эшчәнлек юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләренең бүленеше расланган очракта, бюджет турында карар проектына муниципаль программаларның паспортлары теркәлә.

Әгәр бюджет турында карар проектында бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләре белән кушымта булмаса, бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләре белән кушымта авыл җирлеге бюджеты турында карар проектына аңлатма язуына булган кушымталар составына кертелә.

13. Киләсе финанс елына һәм финанс чорына авыл җирлеге бюджеты проектын төзү авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар, алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла һәм бәяләмә бирү өчен авыл җирлегенең Ревизия комиссиясенә юнәлдерелә.

14. Авыл җирлеге Башкарма комитеты агымдагы елның 15 ноябреннән соңга калмыйча киләсе финанс елына һәм план чорына Авыл җирлеге бюджеты турында карар проектын район Советына карау өчен кертә.

15. Авыл җирлеге бюджеты турында карар проектын карауның һәм аны раслауның авыл җирлеге Советы муниципаль норматив хокукый актында билгеләнгән тәртибендә бюджет турында карарның киләсе финанс елының 1 гыйнварыннан үз көченә керүе, шулай ук аталган карар белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 статьясы нигезендә күрсәткечләрнең һәм сыйфатламаларның раслануы күздә тотылырга тиеш.

16. Авыл җирлеге бюджеты турында карар, әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм (яки) авыл җирлеге бюджеты турында карарда башкасы каралмаса, 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм финанс елының 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

Авыл җирлеге бюджеты турында карар билгеләнгән тәртиптә аңа имза салынган көннән соң ун көннән соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.

17. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары авыл җирлеге бюджетының балансланган булуын һәм бюджетка бәйле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салу, бюджет процессын гамәлгә ашыру, кытлык күләме, муниципаль бурыч күләме һәм структурасы, авыл җирлегенең бюджет йөкләмәләре үтәлеше буенча билгеләнгән федераль законнарның һәм Татарстан Республикасы законнарының үтәлүен тәэмин итә.

18. Авыл җирлеге бюджеты керемнәре Россия Федерациясенең бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турында законнар һәм бүтән төрле мәҗбүри түләүләр турында законнар нигезендә формалаша.

19. Авыл җирлеге бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган формаларда гамәлгә ашырыла.

20. Федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен финанслау өчен авыл җирлеге бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру рөхсәт ителми, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан тыш.

21. Муниципаль мөлкәт объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 73 статья. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китертүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнә.

### 74 статья. Авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчалары

1. Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен гражданнар тарафыннан бер тапкыр түләнгән түләүләр аңлашыла. Гражданнарның үзара салым тәртибендәге түләүләренең күләме авыл җирлегендә (авыл җирлеге составына керүче торак пунктында) яшәүче һәммәсе өчен зурлыгы буенча абсолют тигез итеп билгеләнә, авыл җирлегендә (авыл җирлеге составына керүче торак пунктында) яшәүчеләрнең гомуми исәбендә 30 процентыннан артып китә алмый торган күләмдәге аерым категория гражданнарыннан һәм үзләре өчен түләүләр күләме киметелергә мөмкин булганнардан тыш.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бер тапкыр түләнә торган түләүләрне кертү һәм файдалану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә.

### 75 статья. Авыл җирлегенең алынган муниципаль бурычлары (муниципаль әҗәте)

1. Авыл җирлеге бюджетындагы кытлыкны финанслау һәм әҗәт йөкләмәләрен каплау максатында авыл җирлеге федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә эчке муниципаль әҗәткә алып торуларны гамәлгә ашырырга хокуклы.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлеге исеменнән муниципаль әҗәткә алуны гамәлгә ашыру хокукына ия була.

3. Авыл җирлеге бюджетында агымдагы финанс елы башына калган акчалар авыл җирлеге Советының хокукый актында билгеләнә торган күләмдә агымдагы финанс елында вакытлы касса аермаларын каплау һәм, авыл җирлеге бюджеты турында авыл җирлеге Советы карарында каралган очракларда, товарлар китертүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә авыл җирлеге исеменнән төзелгән, хисаплы финанс елында әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактларны түләүгә күрсәтелгән максатларга тотылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдык суммасыннан артмаган күләмдә бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелергә мөмкин.

### 76 статья. Авыл җирлегенең җирле бюджетын үтәү

1. Авыл җирлегенең җирле бюджетын үтәү Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Авыл җирлеге бюджеты кассаның бердәм һәм чыгымнарның ведомство буйсынуында торуы нигезендә үтәлә.

3. Авыл җирлеге бюджетын үтәүнең касса хезмәтләрен күрсәтү, авыл җирлеге бюджетыннан акча алучыларның шәхси счетларын ачу һәм алып бару Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Авыл җирлеге бюджетын үтәү авыл җирлегенең irекле бюджет исемлеге һәм авыл җирлегенең касса планы нигезендә оештырыла.

## 77 статья. Бюджет хисаплылыгы. Авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисап

1. Авыл җирлегенең бюджет хисаплылыгы еллык була.

2. Авыл җирлегенең бюджет хисаплылыгы авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының иркле бюджет хисаплылыгы нигезендә төзелә.

3. Авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисап авыл җирлеге Советы карары белән расланырга тиеш.

4. Авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисап аны авыл җирлеге Советына тапшырганчыга кадәр тышкы тикшерүгә тиеш, ул бюджет акчаларының баш администраторларының бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерүне һәм авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә ала.

Авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисапны тышкы тикшерү авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе яки авыл җирлеге Советы тарафыннан авыл җирлеге Советы билгеләгән тәртиптә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

5. Авыл җирлеге Башкарма комитеты, агымдагы финанс елының 1 апреленнән соңга калмыйча, аңа бәяләмә әзерләү өчен авыл җирлеге бюджетын үтәү турында хисап тапшыра. Авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү бюджет акчаларының баш администраторларының еллык бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерү белешмәләренә нигезләнеп, 1 айдан артмаган срокта уздырыла.

6. Авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисапка бәяләмә бер үк вакытта авыл җирлеге Башкарма комитетына юллап, авыл җирлеге Ревизия комиссиясенә тапшырыла.

7. Ел саен, агымдагы финанс елының 1 маеннан соңга калмыйча, авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлеге Советына, хисаплы финанс елына авыл җирлеге бюджетын үтәү турында авыл җирлеге Советы карары проектын, авыл җирлеге бюджетын үтәү турында бүтән финанс хисаплылыгын һәм Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган бүтән документларны теркәп, хисаплы финанс елына авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисап тапшыра.

8. Авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча авыл җирлеге Советы авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисапны раслау турында яки кире кагу турында карар кабул итә.

Авыл җирлеге Советы авыл җирлеге бюджетын үтәү турында еллык хисапны кире каккан очракта, ул төгәл булмаган яки белешмәләрне тулы булмаган күләмдә күрсәтү фактларын бетерү һәм 1 айдан артмаган срокта яңадан тапшыру өчен кайтарып бирелә.

9. Авыл җирлеге бюджетын үтәү турында карарда, авыл җирлеге бюджетының гомуми керемнәр, чыгымнар һәм кытлык суммасын күрсәтеп, хисаплы финанс елына авыл җирлеге бюджетын үтәү турында хисап раслана.

Хисаплы финанс елы өчен авыл җирлеге бюджетын үтәү турында авыл җирлеге Советы карарына аерым кушымталар белән түбәндәгеләрнең күрсәткечләре раслана:

бюджетларның керемнәр классификациясе кодлары буенча авыл җирлеге бюджеты керемнәренең;

авыл җирлеге бюджеты керемнәренә карый торган дәүләт идарәсе секторы операцияләренең керем төрләре, керем төрчәләре кодлары, классификацияләре буенча авыл җирлеге бюджеты керемнәренең;

авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының;

бюджетлардагы чыгымнар классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының;

бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының классификация кодлары буенча авыл җирлеге бюджетындагы кытлыкны финанслау чыганакларының;

бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының төркемнәре, төркемчәләре, статьялары, төрләре кодлары буенча авыл җирлеге бюджетындагы кытлыкны финанслау чыганакларының;

бюджетлардагы кытлыкны финанслау чыганакларына карый торган дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясенең.

### 78 статья. Муниципаль финанс контроле

1. Муниципаль финанс контроле Россия Федерациясе бюджет законнарының һәм бюджетка бәйле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы бүтән норматив хокукый актларның үтәлүен тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Муниципаль финанс контроле тышкы һәм эчке, беренчел һәм аннан соңгыга бүленә.

2. Бюджетка бәйле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә тышкы муниципаль финанс контроле авыл җирлеге Ревизия комиссиясенең контроль эшчәнлеге булып тора.

3. Бюджетка бәйле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле авыл җирлеге Башкарма комитеты органнары (вазыйфаи затлары) булып торган муниципаль финанс контроле органнарының контроль эшчәнлеге булып тора.

4. Беренчел контроль авыл җирлеге бюджетын үтәү барышында бюджетны бозуларны кисәтү һәм чикләү максатларында гамәлгә ашырыла.

5. Аннан соңгы контроль үтәлүенең законлы, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның төгәл булуын билгеләү максатларында авыл җирлеге бюджетын үтәү нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

## XIV БҮЛЕК. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫН КАБУЛ ИТҮ. ӘЛЕГЕ УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ

### 79 статья. Авыл җирлеге Уставы проектын әзерләү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе

1. Авыл җирлеге Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында авыл җирлеге Советы карары проекты авыл җирлеге Советына авыл җирлеге

Башлыгы, авыл җирлеге Советы депутатлары, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан кертелергә мөмкин.

2. Авыл җирлеге Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен авыл җирлеге Советы тарафыннан махсус комиссия төзелергә мөмкин. Аталган комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре, экспертлар чакырылырга мөмкин.

3. Авыл җирлеге Уставы проекты, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты авыл җирлеге Уставын кабул итү, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында мәсьәләне карау көненә кадәр кимендә 30 көн калганчы аталган Устав проекты бер үк вакытта аталган муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алуның авыл җирлеге Советы билгеләгән тәртибен, шулай ук аның хакта фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен бастырып (халыкка белдереп), рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш. Авыл җирлеге Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл тәгъбирләү формасында үзгәрешләр кертелгән очракта, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук аның хакта фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) таләп ителми.

4. Авыл җирлеге Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында авыл җирлеге Советы карары проекты буенча аларны авыл җирлеге Советы утырышында карау алдыннан әлеге Устав нигезендә гавами тыңлаулар уздырыла, Уставка үзгәрешләр фәкать Уставта беркетелә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясенә һәм федераль законнарга туры китерү максатларында үзгәрешләр кертелгән очраклардан тыш.

## 80 статья. Авыл җирлеге Уставын кабул итү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе

1. Авыл җирлеге Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын карау авыл җирлеге Советы Регламенты нигезендә кимендә ике укылышта авыл җирлеге Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Авыл җирлеге Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проекты беренче укылышта кабул ителгәннән соң, аталган проект авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан авыл җирлеге Советы депутатларына, хокукый иҗат инициативасына хокуклы бүтән субъектларга төзәтмәләр кертү өчен җибәрелә.

3. Авыл җирлеге Уставы, Уставка үзгәрешләр кертү турында авыл җирлеге Советы карары авыл җирлеге Советына билгеләнгән депутатлар исәбендә өчтән ике өлеше күләмендә күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

## 81 статья. Авыл җирлеге Уставының, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карарның үз көченә керү тәртибе

1. Авыл җирлеге Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында авыл җирлеге Советы карары, алар кабул ителгәннән соң, авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен муниципаль берәмлекләрнең уставларын теркәү өлкәсендәге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына җибәрелә.

2. Авыл җирлеге Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында авыл җирлеге Советы карары, муниципаль берәмлекнең контроль органын булдыруны күздә тотучы үзгәрешләр аларны дәүләт теркәвенә алганнан соң рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка белдерелергә) тиеш һәм рәсми бастырып чыгарылганнан соң (халыкка белдерелгәч) шунда ук үз көченә керә. Әгәр авыл җирлеге Башлыгы хәл итүче тавыш хокукы белән авыл җирлеге Советы рәисе вәкаләтләрен башкара икән, авыл җирлеге Башлыгы тавышы авыл җирлеге Уставын, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткәндә авыл җирлеге Советы депутаты тавышы кебек кабул ителә.

3. Әлеге Уставка кертелгән, җирле үзидарә органнары структурасын, җирле үзидарә органнары арасындагы вәкаләтләрнең бүленешен үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр (Уставны федераль законнарга туры китерү, шулай ук җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының вәкаләтләрен, вәкаләтләре срогын, аларны сайлау тәртибенә үзгәрешләр кертелгән очраклардан тыш) әлеге Уставка аталган үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокукый актны кабул иткән авыл җирлеге Советы вәкаләтләренең срогы тәмамлану белән үз көченә керә.

3.1. Әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, алар түбәндәгечә рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) авыл җирлеге Советының аның рәисе яки авыл җирлеге Башлыгы яисә авыл җирлеге Советы рәисе вәкаләтләрен башкаручы авыл җирлеге Башлыгының берүзе генә имзалаган карары;

2) авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән һәм авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан имзаланган аерым норматив хокукый акт. Бу очракта әлеге хокукый актка аны кабул итү турында авыл җирлеге Советы карары реквизитлары куела. Авыл җирлеге Советының мондый карарына әлеге Уставка кертелә торган үзгәрешләрнең һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турында күчеш нигезләмәләрен һәм (яки) нормаларын кертү рөхсәт ителми.

4. Уставка кертелгән һәм контроль орган булдыруны күздә тоткан үзгәрешләр һәм өстәмәләр әлеге статьяның 2 пунктында каралган тәртиптә үз көченә керә.

5. Авыл җирлеге Уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Әгәр федераль законда, Татарстан Республикасы законында аталган срок күрсәтелмәсә, авыл җирлеге Уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү срогы тиешле федераль законның, Татарстан Республикасы законының үз көченә керү датасын, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектын рәсми бастырып чыгару (халыкка

белдерү) һәм аның турында гавами тыңлауларда фикер алышу зарурлыгын исәпкә алып, аның буенча гражданнарның тәкъдимнәрен, авыл җирлеге Советының утырышлар ешлыгын, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәвенә алу һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм, кагыйдә буларак, алты айдан артып китәргә тиеш түгел.

6. Әлеге Уставны әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актта яңа редакциядә бәян итү рөхсәт ителми. Бу очракта яңа Устав кабул ителә, ә элегрәк гамәлдә булган авыл җирлеге Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар авыл җирлегенең яңа Уставы үз көченә кергән көннән башлап көчен югалткан дип таныла.